# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ 4/ 2021

Батик – гамәли сәнгатьнең тукымаларны бизәүгә нигезләнгән бер төре, индонезия теленнән ул «балавыз тамчысы» дип тәрҗемә ителә. 2009 елда ЮНЕСКО пумала белән тукыма бизәкләү сәнгатен кешелекнең рухи мирасы шедеврлары рәтенә кертте




ФЕСТИВАЛЬ
НОВЫЙ ГОД







*Лилия*
*КАШАПОВА-ИСКУЖИНА*

# Ак телəклəр

*Яңа елда ап-ак карлар ява...*
*Ак телəклəр ява, күрегез...*
*Һəрбер йортка ак бəхетлəр булып,*
*Сафлык, шатлык булып керегез!*
*Битлəремə кунып, сөендереп,*
*Керфек очларында эрегез.*
*Нечкə тойгыларым, шигырь булып,*
*Йөрəгемне моңга төрегез.*
*Балаларым, оныкларым өчен*
*Телəгəнне берүк бирегез.*
*Сүнмəс йолдыз, шатлык, бəхет булып,*
*Изгелеклəр булып керегез!*



**Рəсемнəрдə: Кукмара шəһəренең Комсомол мəйданында узган районара «Кукмара итеклəре-2021» фестиваль-күргəзмəсеннəн (#ITEKFEST) күренешлəр**
**Фоторəсемнəр kukmor-rt.ru сайтыннан алынды**

# Түгәрәк уен

№ 4 2021

*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*

16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 04.12.2021
Чыгу көне: 15.12.2021
Заказ: 017381
Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:
420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта:** Батиклар. *Рәссам Дилә Барышева*

© «Түгәрәк уен», 2021

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

4 **«Мөслим тугайлары» – традицияләр**

8 **«ISTELEK» иҗади берләшмәсе Татарстан буйлап гастрольләрен башлады**

**«Казан егетләре» Татарстан районнары буйлап музыкаль сәяхәткә чыкты**

9 **Җыр һәм бию дәүләт ансамбленнән – «Мирас. Алтын фонд»**

## КҮРГӘЗМӘ

10 Р. Мөхәммәтова
**Каюлы кун – гасырлар төпкеленнән килгән гүзәл мирас**

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ

16 Ф. Хуҗин
**Каз канатларын эзләргә Төштем су буйларына...**

19 С. Әхмәтҗанова
**Көз сагышы – каурый моң...**

20 Р. Сәйфетдинова
**Йон эрләүнең җае бар**

## ҺӨНӘРЛЕ УЛМӘС...

23 Е. Шемелева
**Ефәктәге күңел бизәкләре**

28 Ф. Мәрданова
**Алмалы көянтәсенә кунмаган кош калмады**

## ӘДӘБИ МИРАС

32 Л. Мөхәммәтҗанова
**Татар тарихы – халык иҗатында**
















**СӘХНӘ**

38 Р. Исмәгыйлева
**Җырлы гомер**

42 Р. Мөхәммәтова
**Калфагын җуймаган театр**

**КУНАКХАНӘ**

48 *Ф. Лотфуллина*
**Сәйдә Мөхәммәтҗанова: «Мөнәҗәтләр тыңлап үстем»**

**БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ**

53 **Ак елан**

**БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...**

56 Г. Хөсәенова
**Аулак өй**
*(Мәктәпкә хәзерлек төркеме балалары өчен)*

59 **Җәяүле буран** *(Җыр)*

**ӨЙ КҮРКЕ – АШ**

60 **Үрдәк итеннән бәлеш**

**ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ**

64 **Шахворд**

## «МӨСЛИМ ТУГАЙЛАРЫ» – ТРАДИЦИЯЛӘР



«Мөслим тугайлары» фольклор коллективы «Мәдәният» илкүләм проекты кысаларында һәвәскәр иҗат коллективларының Бөтенроссия фестиваль-конкурсында «Традицияләр» номинациясендә гран-прига ия булды. Октябрь аенда ансамбль Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә мастер-класс үткәрде.

Беренчедән, алар үз иҗатларын профессионалларга – Татарстан Республикасының Дәүләт фольклор музыкасы ансамбленә һәм «Бәрмәнчек» Татарстан Республикасы керәшеннәрнең дәүләт фольклор ансамбленә күрсәттеләр. Икенчедән, әлеге коллективларның чыгышларын карап үз иҗатлары белән чагыштыру мөмкинлеге туды. Халык фольклор ансамбле чыгышын, Татарстан Республикасының Дәүләт фольклор музыкасы ансамбле җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов белән «Бәрмәнчек» Татарстан Республикасы керәшеннәрнең дәүләт фольклор ансамбле баш дирижеры Эрдни Чавлинов карап, үз киңәшләрен бирделәр. Шулай ук, бирегә халык музыкасы, этномузыкология, инструменталь башкару өлкәсендә әйдәп баручы белгечләрнең, традицион костюм тегү һәм реконструкцияләү белән шөгыльләнүче һөнәрчеләр һәм дизайнерларның лекцияләре булды. Сәхнә киеме буенча модельер-конструктор Руслан Габов Мөслим ансамбле мисалында фольклор коллективларына киемнәр тегү үзенчәлекләрен аңлатты.

Гран-при коллективка киемнәрне яңартырга һәм инструментлар алырга мөмкинлек биргән.

Проект В.Д. Поленов исемендәге Россия Халык иҗаты йорты оештырган грант



конкурсы кысаларында тормышка ашырыла. Мастер-класс Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге ярдәмендә үткәрелде.

***«Мөслим тугайлары» коллективы җитәкчесе Фәнис АБДУЛЛИН белән хәбәрчебез әңгәмәсе***

– Ансамбль 1986 елда оешты. Димәк, 36 нчы ел эшләп килә. Халык ансамбле булса да, күпмедер дәрәҗәдә профессиональ дип горурлана алабыз. Чөнки ул башта район музыка мәктәбе кысаларында укытучылар белән оештырылган иде. Соңрак Зифа Басыйрова исемен йөрткән район мәдәният йорты карамагына күчте. Хәзер безгә мәдәният йортындагы һәвәскәрләр дә кушылды. Аларның күбесе музыкаль белемлеләр.

**– Коллективның нигезендә торган кешеләр калдымы әле?**

– Алмашынып тора дисәң дә була. Аны башлап җибәрүчеләрдән ике кеше калды – мин һәм Мөҗәһит Әхмәтҗанов. Бездән берничә ел соңрак Дилбәр Рифкатовна килде. Башкалар инде соңрак кушылучылар.











**– Хәзер коллективта ничә кеше?**

– 19да булабыз, 24тә.

**– Ни өчен нәкъ менә фольклор ансамбле?**

– «Сорнай» ансамблен күреп, кызыгып оештырдык. Исемен уйладык-уйладык та, безнең Мөслим бик матур урында урнашкан, «Мөслим тугайлары» дип исем куштык.

**– Визит карточкасы булган номерларыгыз бармы?**

– Безнең 100дән артык көебез бар. 30 ел буе җырлаган җырыбыз юк, гел алмаштырып торабыз. Элеккеге көйләрне эзләп табабыз.

**– Репетицияләргә кайчан җыеласыз?**

– Дәүләт ансамбльләре кебек иртүк репетицияләр ясый алмыйбыз. Безнең катнашучыларыбызның һәрберсенең эше бар. Кич җыелып алабыз. Әле анда да төрле эшләре чыгып тора. Үзешчәннәрнең шул авырлыклары бар. Вакытыбыз күбрәк булса, уңышларыбыз да зуррак булыр иде.

**– Иҗатыгызны кайларда тәкъдим итәсез?**

– Күп җирләрдә булдык – Чабаксар, Түбән Новгород, Киров шәһәрләрендә, Азәрбәйҗанда чыгыш ясадык. Район хакимияте безне төрле җирләргә йөртә.

**– Мөслимдә концертлар куясызмы?**

– Район күләмендә үткән барлык мәдәни чараларда катнашабыз.

**– Ә грантка кадәр костюмнарны ничек тектерә идегез?**



– Район хакимияте булыша иде. Безнең хәзер өч пар киемебез бар. Өченчесен яңа тектердек.

**– Грант акчасы җиттеме?**

– Әйе. Әле баяннар да алдык. Тагын булса да ярар иде – курайларны яңартасы бар, әле берне генә кайтарып карадык. Алар 12шәр мең сум тора, кыйммәт. Кубызлар да кирәк, күбрәк булса, күбрәк кеше уйный алыр иде.

**– Инструментларны табып буламы?**

– Безгә Төркиядән өч саз, барабан алып кайтып бирделәр. Мөселман илләреннән эзлибез инде. Сорнай белән кубызны Санкт-Петербургтан кайтардык.

**– Ә милли киемнәрне кайда тектергегез?**

– Казанда. Ул безгә 850 мең сумга төште.

**– Алдагы көннәргә планнарыгыз?**

– Мәскәүгә җыенабыз. Грант откан коллективлар Мәскәүдә чыгыш ясаячак. Безнең номер әзер инде.

**– Коллективыгызга уңышлар телибез.**





## «ISTELEK» ИҖАДИ БЕРЛӘШМӘСЕ ТАТАРСТАН БУЙЛАП ГАСТРОЛЬЛӘРЕН БАШЛАДЫ




«ISTELEK» иҗат берләшмәсе беренче концертларын Кукмара мәдәният йортыннан башлады. Киләсе концертлар Лаеш, Яшел Үзән районнарында булачак. «ISTELEK» (истәлекләр) – этно-фьюжн юнәлешендәге музыкаль төркемнәрнең иҗади берләшмәсе. Концерт программасын фольклор һәм электрониканы органик рәвештә берләштереп, заманча музыка башкаручы яшьләр иҗаты тәшкил итә. ZAKARIA фольклор төркеме; удмурт телендә автор-башкаручы Shoner Paul; заманча татар музыкасын андеграунд стилендә башкаручы Илгиз Шәйхразиев; популяр Казан ди-джее Malsi Music шундыйлардан. Тамашачылар концертта татар, рус, башкорт, удмурт, мордва, мари, керәшен, чуваш мәдәнияте белән таныша. Тамашачыларны Татарстан халыкларының туган телләре белән таныштыру максатыннан концерт программасы интерактив белән бизәлгән.

## «КАЗАН ЕГЕТЛӘРЕ» ТАТАРСТАН РАЙОННАРЫ БУЙЛАП МУЗЫКАЛЬ СӘЯХӘТКӘ ЧЫКТЫ

«Казан егетләре» музыкаль төркеме яңа программа белән республика районнарында гастрольләрдә булды. Концертлар Аксубай, Лаеш, Питрәч мәдәният йортларында үтте.

Тамашачы музыкаль төркем башкаруында «Тала-тала», «Җомга», «Ак чәчәкләр», «Яшьлегемә кайтам», «Каеннарым» һәм башка популяр җырларны яратып тыңлады.

Төркемнең яңа проекты Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге белән берлектә әзерләнде. Аның максаты – туган якка мәхәббәт тәрбияләү һәм һәр район турында җырлар аша төбәкләрнең потенциалын ачу.



## ЖЫР ҺӘМ БИЮ ДӘҮЛӘТ АНСАМБЛЕННӘН – «МИРАС. АЛТЫН ФОНД»

Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле «Мирас. Алтын фонд» концерт программасы белән узып баручы елга нәтиҗә ясады – коллектив үз тамашачысын Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына җыйды.

Концерт өчен ул «Без – татарлар» исемле яңа вокаль-хореографик номер әзерләгән. Ансамбль коллекциясе шедеврлары – тирән фольклор тамырлары булган чыгышлар белән бергә яңа вокаль-хореографик композицияләр сайланган. Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле каршында эшләп килгән балалар студиясенә йөрүчеләр дә сәхнәгә чыкты – «Әлипә» һәм быелгы премьера – «Яз килә» башкарылды.

Ансамбльнең XIX гасыр азагы – XX гасыр башындагы Казан һәм Себер татарларының фольклор-этнографик материалларына нигезләнгән, «Туй» музыкаль-хореографик спектакленә ихтыяҗ зур – коллектив аны кая гына алып барса да, тамашачы яратып карый. Премьера өчен тарихи материаллар буенча 300ләп костюм тегелгән, чорны чагылдыру өчен этник инструментлар сатып алынган иде. «Мирас. Алтын фонд» программасының нигезенә дә шушы музыкаль-хореографик спектакль салынган.

2022 елда ансамбльгә 85 яшь тула. Юбилей уңаеннан ансамбль яңа программа әзерли.

### ОНЛАЙН ОСТАХАНӘ БИЕРГӘ ӨЙРӘТӘ

Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле татар этнографик биюләрен өйрәнү өчен яңа онлайн остаханә тәкъдим итә. Биюләрне өйрәнергә теләгән һәркем ансамбльнең социаль челтәрләрендәге сәхифәсе аша өйрәнә ала.

Ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов: «Остаханә аша халыкка милли биюләр өйрәтәсебез килә. Нинди хәрәкәтләр бар – барысы да видеоязмада аңлатыла. Язмалар You Tube, TikTok һәм башка сәхифәләребезгә урнаштырылачак, диск буларак та чыга. Авылларда концертлар куеп йөргәндә, балаларга бушлай остаханәләр уздырдык. Барлыгы сигез мастер-класс эшләдек».

Биюләрне Татарстанның халык артисты, баш балетмейстер Раилә Гарипова, Татарстанның халык артисты Равил Габдрахманов, балетмейстерлар Ләйсән Хәмитова, Айрат Хәмитов күрсәтә.

Остаханә дәүләт гранты хисабына эшләнгән. Алар татар һәм рус телләрендә алып барыла.



Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан



*Рузилә МӨХӘММӘТОВА*

# КАЮЛЫ КҮН – *гасырлар төпкеленнән килгән гүзәл мирас*



ТӨРЛЕ МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ЧОРЛАР РАРИТЕТЛАРЫН ҮЗЕНӘ ТУПЛАГАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ МУЗЕЕНЫҢ ИҢ ЗУР ГОРУРЛЫГЫ – ТАТАР КОЛЛЕКЦИЯСЕ. БҮГЕНГЕ КӨНДӘ ЭТНОГРАФИЯ, ТРАДИЦИОН СӘНГАТЬ ҺӘМ КАЗАН ТАТАРЛАРЫ ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУ АРТТЫ, БУ ТУРИЗМ ҮСЕШЕНӘ ҺӘМ ҺӨНӘРЧЕЛЕКНЕҢ КАЙБЕР ТӨРЛӘРЕ ТОРГЫЗЫЛУГА БӘЙЛЕ. БУ ОЧРАКТА ЮВЕЛИР СӘНГАТЕ, КАЮЛЫ КҮН, ТУКУЧЫЛЫК ҺӘМ ЧИГҮ БУЕНЧА МУЗЕЙ ТУПЛАНМАЛАРЫ СӘНГАТЬ БЕЛГЕЧЛӘРЕ, КУЛЬТУРОЛОГЛАР, ХАЛЫК ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕ БЕЛГЕЧЛӘРЕ ӨЧЕН АЛЫШТЫРГЫСЫЗ ЧЫГАНАК БУЛЫП ТОРА.





Татарның каюлы күне – гасырлар төпкеленнән мирас булып килгән үзенчәлекле сәнгати традиция. Казан сафьяны осталары йомшак күн эшкәртү рецептын буыннан буынга күчергән, ә талантлы читекчеләр читек ясау һөнәрен милли бизәкләрнең кипмәс коесына әверелдерде.

Татарстан Республикасы Милли музеенда быелның июнь аеннан башлап октябрьгә кадәр «Татарларның каюлы күне: кәсеп, традиция һәм сәнгать» исемле күргәзмә эшләде. Ул Казан татарларының бөтен дөньяга танылган – XIX гасырда һәм XX гасыр башында Европада, Азиядә һәм хәтта Америкада да киелгән – бизәкле аяк киеме җитештерү тарихына багышланган иде. 200ләп экспонатның күбесе беренче тапкыр күрсәтелде.

Татарстан Республикасы Милли музееның күн мозаика коллекциясе – Россиядә генә түгел, дөньяда иң зурысы. Музей тупланмалары нигезендә төзелгән күргәзмәдә Казанда һәм аның тирә-ягында XVIII гасыр азагыннан XX гасыр башына кадәрге аралыкта каюлы күн җитештерү этаплары чагылыш тапкан, традицион читекләрнең совет чорында җитештерелүе дә күзәтелә. Күнчеләрнең һәм каючыларның эш кораллары һәм эшләнмә үрнәкләре бары тик кулдан башкарыла торган уникаль казан җөе техникасын вакыт агышы үзгәртә алмавын күрсәтә.

1925 елда Париж Бөтендөнья күргәзмәсенең Татар Республикасы стендына куелган көмеш һәм ефәк белән чигелгән данлыклы читек үрнәкләре дә бар иде күргәзмәдә. Авторлар каюлы читекләрне кием комплексында күрсәтергә тырышкан, ә бу инде Казан татарлары киеме генә түгел, чөнки «азиат аяк киеме» Урта Азия халыкларында да бик популяр булган. Экспедицияләр Казан татарларының традицион сәнгатен һәм һөнәрләрен ныграк танытырга һәм халык сәнгате артефактларының сәнгати әһәмиятен аңларга булышкан. Тора-бара татарның каюлы читекләре Казан татарларының мәдәниятенә һәм көнкүрешенә багышланган музей коллекцияләрендә һәм ТССР Үзәк

музееның Этнографик бүлегендә лаеклы урынын ала. Алга таба коллекция зурая, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының экспедицияләреннән кайткан әйберләр белән тулылана, гаиләдә сакланган чигүле читекләрне музейга кешеләр дә бүләк итеп китерә.

Каюлы күнгә бәйле бүгенге вазгыятьне күрсәткән заманча бүлек аеруча игътибар үзәгендә булды – биредә күн мозаикасы белән модалы аксессуарлар һәм интерьер предметлары ясаган рәссамнарның гаҗәеп иҗаты куелган иде. Музей эшчәнлеге татар каюлы күн традицияләренең саклануында һәм әлеге борынгы һөнәрнең яңаруында зур роль уйный: алтмышынчы елларда музей коллекцияләренә рәссам Софья Кузьминых мөрәҗәгать итә. Ул беренчеләрдән булып күн мозаикасын заманча декоратив-гамәли сәнгать төре буларак тәкъдим итә. Күннән модалы аксессуарлар һәм аяк киеме ансамбле, интерьер предметлары белән беррәттән ул борынгы «казан җөе» техникасы белән тегелгән бизәк элементларын да кертә. Күп төслелеге һәм сыгылмалылыгы белән аерылып торган орнаментлар, борынгы җөй мөмкинлекләре белән кушылып, рәссамнарның игътибарын җәлеп итә – шулай итеп яңадан-яңа аксессуарлар барлыкка килә, иҗтимагый интерьерларга күн мозаикасы әсәрләре керә. Музей бу һөнәрнең тарихның яңа этабында торгызылуын чагылдырырга омтыла – 1950-1990 нчы елларда «Спартак» аяк киеме фабрикасы һәм Арча җитештерү берләшмәсенең продукциясе үрнәкләрен үз коллекциясенә ала – болар меңәрләгән пар итеп чыгарылган читекләр һәм чүәкләр. Димәк, кулдан тегелгән читек-чүәкләрне кию традициясен халык югалтмаган. 1990 нчы еллардан башлап музей тупланмаларының төп акценты – күн мозаикасы техникасы белән эшләүче профессиональ рәссамнар һәм осталарның авторлык эшләнмәләре. Әлеге иҗатчылар – декоратив-гамәли сәнгатьтә танылган рәссамнар Софья Кузьминых, Әлфия Җәмилова, Светлана Гарбузова, Илдус Гайнетдинов, Наилә Кумысникова. Күн мозаикасы техникасында ясалган декоратив паннолар, төрле интерьер предметлары даими экспозицияләрдә урын



алган, вакытлы күргәзмәләрдә дә аларга сорау зурдан.

100 ел дәвамында музейда җыелган коллекция татар каюлы күне традицияләрен саклауда һәм әлеге борынгы һөнәргә кызыксыну уятуда зур роль уйный. Бүгенге көндә бу сәнгать төре Н. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесында белем алган рәссамнар тарафыннан үстерелә – аларның иң яхшы эшләре күргәзмәнең аерым бер бүлеген тәшкил итте.

Күргәзмә лекцияләр, осталык дәресләре, тематик экскурсияләр һәм презентацияләр өчен дә мәйданчыкка әверелде. 12 августта Лилия Саттарова «Татарларның каюлы күне: мирас һәм милли бренд» исемле лекция укыды, Н. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы педагогы Екатерина Куратова «Татарларның каюлы күн серләре» дип аталган осталык дәресе бирде.

Күргәзмә эшчәнлегенә агымдагы елның 21 октябрендә «Татарларның каюлы күне: милли брендны саклау һәм үстерү проблемалары» дип аталган түгәрәк өстәл






утырышында нәтиҗәләр ясалды. Белгечләр кайчандыр Казанны данлаган уникаль һөнәрчелекнең бүгенге халәтен бәяләде. Түгәрәк өстәлнең модераторы Татарстан Республикасы Милли музееның фәнни эшчәнлек буенча генераль директоры урынбасары Светлана Измайлова иде. Утырышта Татарстан Республикасы Милли музееның генераль директоры вазифаларын башкаручы Алиса Вяткина, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге директоры Алсу Мифтахова, Н. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы директоры Ольга Гыйльметдинова, Татарстан Республикасы Милли музееның генераль директоры урынбасары Лилия Саттарова, Казан дәүләт мәдәният институты доценты Рада Сәләхова, сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова, рәссам-дизайнер Солтан Салиев һәм башкалар катнашты.

**Алсу Мифтахова:** «Халык һөнәрчелеге һәм кәсепчелеге турында» Татарстан Республикасының 3-ЗТР номерлы законы нигезендә Мәдәният министрлыгында Халык һөнәрчелеге буенча сәнгать-эксперт советы эшли. 2020 елдан халык һөнәрчелеге осталары өчен республика галимнәре катнашында укыту-гамәли семинарлары үткәрелә башлады. Әйтик, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты белән берлектә «Татарстанның декоратив-гамәли сәнгате: традицияләр һәм инновацияләр» дип аталган семинар оештырылды. 2021 ел дәвамында күчмә семинарлар үтте.

Быел халыкара белгечләр, этно-дизайнерлар катнашында беренче тапкыр I Этно-fashion фестиваль оештырылды. Фестиваль кысаларында бизнес-программалар, мастер-класслар, ярминкә һәм күргәзмәләр








үтте, Россия һәм якын чит илләрдәге этно-дизайнерларның коллекцияләре тәкъдим ителде. Быел Болгар биләмәләрендә беренче тапкыр Ага-Базар этно-фестивале узды.

Бүгенге чынбарлык шуны күрсәтә: регионның мәдәни һәм рухи ресурслары – матди һәм матди булмаган мәдәни мирасы аның үсеш факторы булып тора. Ә безнең бурычыбыз – республиканың төп халыкларының бай мәдәни мирасын саклау һәм дөньяга тарату.

Халыкның традицион һөнәрчелеген торгызучыларга Министрлык булышырга тиеш, диләр. Без грантлар белән ярдәм итәбез. Быел, мәсәлән, 36 гариза керде – бу күп түгел. Әле бит Россия грантлары да бар. Теләге булган кеше ул грантны таба, теләге булмаганнар зарлана гына. Нәрсәдер алу өчен каядыр мөрәҗәгать итәргә кирәк».

**Ольга Гыйльметдинова:** «СССРда каюлы күн җитештерү белән артельләр, предприятиеләр шөгыльләнсә, бүген милли традицияләрне дәвам итү аерым энтузиастлар җилкәсендә. Безнең уку йорты аларга һөнәр бирә. Әмма аларга алга таба һөнәрләре буенча эшләү мөмкинлеге бармы соң? Грантларны, туристик маршрутларны берләштергән система булдыру сорала. Иҗатчыларны, сатучыларны һәм сатып алучыларны бер бөҗрага туплаган кластерлар оештырырга вакыт җиткәндер».

**Рауза Солтанова:** «Кайчакта безнең читекләребезне үзбәкнеке, казахныкы дип тәкъдим ителүен күрәбез. Үз традицияләребезне саклау һәм таныту буенча башкарасы эшләребез байтак. Төрки халыкларда булган бүгенге тәҗрибәне исәпкә алып эшләгән вакытта гына без бу өлкәдә үзгәреш кичерербез дип уйлыйм. Үзбәкстанда чигү сәнгате бик алга киткән, ул бүгенге көн модасында ярылып ята. Казахстанда шулай ук күн эшкәртү һәм киез басу популяр. Бездә каюлы күн эшләнмәләре зур модага кермәгән. Без әле Татарстанда дизайнерлар, модельерлар традицион сәнгатебезгә игътибар итә дип мактана алмыйбыз. Әлеге күргәзмә аша күп нәрсә өйрәнеп булыр иде. Икенчедән, сәнгати белем алу мәсьәләсе бар. Безнең мәктәпләрдә татар милли сәнгатен өйрәнү компоненты юк, аерым алганда, күн мозаикасы турында сүз бара. Ниндидер энтузиастлар бар, ләкин милли традицияләрдә тәрбияләү программасы юк. Мине Лениногорск сәнгать мәктәбе сөендерде, мәсәлән – аларда тукучылык предметы керә башлаган. Бу юнәлештә киң масштаблы эшләр башкарасы иде. Рәссам-модельер, күн мозаикасы рәссамы һөнәре алып чыгучылар белән максатчан эш алып барылмый – чыгарылышлар үз белемнәрен кайда кулланырга белми».

**Лилия Саттарова:** «Каюлы күннең нигезендә халкыбызның гасырлар аша килгән традицияләре яткан кыйммәтле эксклюзив продукт булуын кешеләрнең аңына җиткерәсе иде. Монда музей коллекцияләре дә зур роль уйный. Белгечләрнең фикере уртак – «Татарның каюлы күне» күргәзмәсен башка регионнарда һәм илләрдә дә күрсәтергә кирәк».

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

*Фәрит ХУҖИН,*
*Мамадыш, Кече Сөн авылы мәдәният йорты директоры*

# Каз канатларын эзләргә Төштем су буйларына…

«КАЗ ӨМӘСЕ» – БОРЫНГЫ ТАТАР ЙОЛА БӘЙРӘМЕ. АНЫҢ АСЫЛЫНДА КАЗНЫ ӨМӘ БЕЛӘН ЭШКӘРТҮ ЯТА. «КАЗ ӨМӘСЕ» ХАЛЫКНЫҢ БЕРДӘМЛЕГЕН ҺӘМ ЯРДӘМЧЕЛЛЕГЕН КҮРСӘТӘ, КЕШЕЛӘРНЕ БЕРЛӘШТЕРӘ ТОРГАН ЧАРА. БУ БӘЙРӘМ КАЗ ЙОЛКУДА БУЛЫШУ ГЫНА ТҮГЕЛ, ЙОРТ ЭШЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮ ҺӘМ ГАСЫРЛАРДАН БИРЛЕ КИЛГӘН ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ САКЛАУ МӘКТӘБЕ ДӘ.





Каз кеше ияләштергән беренче кошлардан санала. Ата-баба казны бик яратып асраган. Татарлар аны күпләп тоткан. Каңгылдап торган казлар татарның рухына туры килеп тора. Казлар хуҗасын аптыратмый: үзләре су буена төшә, кайткач әзер ризык белән тамагын туйдыра.

Ак кар ятып, җир катыргач, авылларда каз өмәләре башлана – күршеләр һәм туган-тумача җыела. Кешеләр алдагы көнгә каз ите әзерли, каз мамыгыннан мендәр ясый.

Каклаган каз – татар кулинариясенең югары ноктасы. Каз мае да югары бәяләнә – кулинария өчен дә яхшы, өшегәндә яки салкын тигәндә дару буларак та кулланыла. Йортта өйләнәсе егет яки җиткән кыз булса, пар казларны туйга саклыйлар. Татар йортын каз мендәреннән башка күз алдына китереп булмый. Бу гаиләнең җитешле булу билгесе. Камыр ризыгы пешергәндә дә каз каурыйларыннан ясалган пумала белән майлана. Туйга дигән казны да бер ел алдан тозлап киптереп куялар. Туй табынына аларны бизәп чыгаралар – бу табындагы иң тәмле ризыкларның берсе була.

Каз өмәсе буласы көнне йорт бизәлә, борынгы сөлгеләр элене, татар милли бизәкләре белән тукылган паласлар җәелә. Бизәкләп җигелгән атларга утырып, яшь егетләр гармун тартып урам әйләнә. Хатын-кызлар иртүк каз өмәсе буласы йортка җыела. Каз эшкәртү эше уен-көлке, җыр-такмаклар белән гөрләп бара. Әлбәттә, традицион «Каз канаты» җыры башкарыла:

*Каз канаты каурый-каурый,*
*Хатлар язарга ярый;*
*Уйнамагач та көлмәгәч,*
*Бу дөнья нигә ярый?*

*Каз канатларын эзләргә*
*Төштем су буйларына.*
*Су буйларында йөргәндә*
*Син генә уйларымда.*

*Каз канатларын санадым*
*Тезелеп кагынганда.*
*Инде кемнәргә карармын*
*Өзелеп сагынганда.*

*Каз канатын кагынганда*
*Мамыкларын җил ала.*
*Яшь вакыттагы мәхәббәт*
*Мәңгелек булып кала.*



Өмәчеләр эшләгән арада хуҗабикә аш-су әзерли: каз итеннән шулпа кайный, зур ит бәлеше салына, коймак пешә, табынга башка милли ризыклар да куела. Каз мае белән майланган мич коймаклары – бәйрәмнең төп бизәге. Коймаклар белән барлык авыл халкы сыйлана.

Суелган казны хатын-кызлар муены аша өреп кабарталар да, кайнар үтүк белән марля аша үтүклиләр – алай ул бик уңайлы йолкына. Юуның да үз җае бар: башта – кайнар, аннары салкын су белән юалар, суда чайкап эчләрен алалар.

Аннары матур киенгән кызлар казларны көянтәгә элеп су буена төшә. Аларны җырлап егетләр озата бара. Үсмер кызлар чишмә юлына каз каурыйлары сибә – монысы киләсе елга да казлар уңсын өчен эшләнә. Җырлы-биюле уеннар чишмә буенда дәвам итә.

*Кыз балалар каз юалар,*
*Чишмәнең суларында.*
*Каз йөрәген юган кызның,*
*Кем икән уйларында?*
*Кыз балалар каз юалар,*
*Куллары салкын микән?*
*Куллары салкын булса да,*
*Йөрәге ялкын икән.*
*Кыз балалар каз юалар,*
*Карлы-бозлы сулары.*
*Йөрәгемә куеп җылыт*
*Өшегәндер кулларың.*
*Каз өмәсе, каз өмәсе*
*Өмәләргә бараем.*
*Казы – сиңа, кызы – миңа,*
*Үпкәләмә, агаем.*

Кич кызлар яңадан өмә булган йортка җыела. Кич утырганда зур каурыйлардан мамык йолкыйлар, аны мендәр сүресенә тутыралар. Егетләр килә. Аларны иң кыю кызлар каршы алып, каз канаты сатып алырга тәкъдим итә. Кызларның төртмәле сүзләренә чая итеп җавап табарга да кирәк. Каз канаты сатып алучылар кадерле кунак була.

«Каз өмәсе» бәйрәме кыз күзләү өчен менә дигән чара – булачак киленнең уңганлыгы да, өлкәннәр белән мөгамәләсе дә шушында күренә.

Автор фоторәсемнәре

Сания ӘХМӘТҖАНОВА

# Көз сагышы – каурый моң...

*Көзләр җиткәч, казлар гына түгел,*
*Кызлар да бит тала сагышка,*
*«Каз канаты»н көйләп моңсулана,*
*Казлар каңгылдаган тавышка.*

*Каз өмәсе – нигъмәтле көз яме,*
*Борынгыдан килә бу йола.*
*Бер-бер йортта өмә ниятләнсә,*
*Бар авылга якты моң тула.*

*Өмә көнне апа-җиңгәчәйләр*
*Йокысыннан таңда уяна.*
*Бүген без дә искә төшәрбез, дип,*
*Көянтәләр хәтта куана.*

*...Уятыла хәтер, кузгатыла,*
*Вакыт чигенгәндәй тоела.*
*Җанга гүя Киек каз юлыннан*
*Каурый-каурый сагыш коела.*

*Көянтәсе кош сайраткан көйгә*
*Тар сукмактан кызлар агыла.*
*Җилфер-җилфер кызлар итәгенә*
*Каз мамыгы килеп сарыла.*

*Көяз сынын иркә уйнаклатып,*
*Кызлар төшә чишмә буена.*
*Гәрәбәдәй кәрәз сыман казлар*
*Бүләк булыр кемнең туена?*

*Егетләрнең гармун күрегеннән*
*Яшьлек дәрте ташып түгелә.*
*Бөтен дөнья шулчак әйтерсең лә*
*Яшерен сөю-назга күмелә.*

* * *

*Көянтәләр, җырлы көянтәләр*
*Чишмә юлын күптән онытткан.*
*Алма-алма җете бизәкләре*
*Еллар белән уңып боеккан.*

*Сылу кызның иңнәрендә биеп,*
*Су китергән иртә таңнарда;*
*Килен-килендәшнең күпме сере*
*Сеңеп калган икән аларга?*

*Көмеш чыңнар булып чишмә шавы*
*Пар чиләккә җырлап тулгандыр.*
*Яшь кәләшне сөйгәненнән көнләп,*
*Көянтәгә кошлар кунгандыр.*

* * *

*Көянтәләр сыйлы көз җиткәнне,*
*Каз өмәсен озак көттеләр.*
*Бүген менә яшьлек юлларыннан*
*Кош тоткандай җырлап үттеләр.*

*Каз өмәсе гөрли авылымда,*
*Җыр-моң тынмый чишмә буенда.*
*Сөйгән ярлар сүз куешты микән,*
*Очрашырга кичке уенда?*

*Үзебезчә, элеккечә диеп,*
*Каз маенда пешәр коймагы,*
*Каз бәлеше белән сыйланырга*
*Чакырылыр кичкә кунагы.*

*...Көянтәләр менәр чормаларга,*
*Онытылыр тагын беразга.*
*Кызлар үсеп торыр... Казларыбыз*
*Бәбкә чыгарырлар һәр язда!*

*Учлап-учлап сипкән мул каурыйлар*
*Оя-оя казлар юрасын!*
*Онытырга кыймас, саклар авыл*
*Халкымның бу изге йоласын!*

*Рәзинә САЙФЕТДИНОВА,*
*Питрәч, Кибәк Иле авылы мәдәният йорты директоры*

# Йон эрләүнең җае бар

БОРЫН-БОРЫННАН АТА-БАБАЛАРЫБЫЗ САРЫК АСРАГАН. ХАТЫН-КЫЗЛАРЫБЫЗ ИСӘ САРЫК ЙОНЫН АЛГАЧ, ЯЗЫП, ЭРЛӘП, КАТЫП, ҖЫЛЫ ОЕКБАШЛАР-БИЯЛӘЙЛӘР, ӨС КИЕМНӘРЕ БӘЙЛӘГӘН. «ОРЧЫК ӨМӘСЕ» – АТА-БАБАЛАРЫБЫЗДАН КАЛГАН ЙОЛА. УЛ КАРА КӨЗ ҖИТЕП, ҖИРГӘ КАР ТӨШКӘЧ УЗДЫРЫЛА. ХУҖА КЕШЕ КҮП ИТЕП ЙОН ӘЗЕРЛӘП КУЯ. КИЧТӘН ТӘМ-ТОМНАР ПЕШЕРӘ. ӨМӘГӘ КҮРШЕ-КҮЛӘН, ДУС-ИШ ЧАКЫРЫЛА. БЕРГӘЛӘП ҖЫЕЛГАЧ, КҮМӘК ЭШ БАШЛАНА: КЕМДЕР ЙОН ЯЗА, КЕМДЕР ЭРЛИ, КЕМДЕР ЙОМГАК ЧОРНЫЙ, КЕМДЕР БӘЙЛИ. КҮҢЕЛСЕЗ БУЛМАСЫН ӨЧЕН, БОЛАР БАРЫСЫ ДА УЕН-КӨЛКЕ, ҖЫР-БИЮ БЕЛӘН ҮРЕЛЕП БАРА. ЭШЛӘР ТӘМАМЛАНГАЧ, ХУҖА ӨМӘЧЕЛӘРНЕ ТӘМЛЕ РИЗЫКЛАР БЕЛӘН СЫЙЛЫЙ.



Питрәч районы Кибәк Иле авылында яшәүче Әминә апа Нуриева, өлкән яшьтә булуына карамастан, бүген дә тик тормый – йон эрли, бәйли. Мин кергәндә дә ул матур яулыкларын бәйләп, күлмәкләрен киеп, йон эрләргә әзерләнә, кабаны, орчыкны барлый иде.

– Язгы йонны гына эрлиләр, көзгесен эрләп булмый – кыска ул – анысы итек басу өчен генә ярый, – дип сүз башлады Әминә апа. – Йонны язу әллә ни авыр эш түгел, чүпләрен аласың, кабартасың. Иң катлаулысы – эрләү.

Әминә апа язган йонны кабага беркетеп куйды. Каба – агачтан ясалган махсус җайланма. Безнең авылда каба инәсез була, шуның өчен кабага йонны махсус бау белән бәйләп куялар. Кайбер якларда каба очына тимер инә беркетелә, кайберләренә махсус агачтан тарак ясап куела. Безнен якларда аны «ая» дип тә йөртәләр. Бу йон кабадан төшеп китмәсен өчен кирәк.

Әминә апа элек ничек итеп йон язганнарын яки теткәннәрен сөйләп китте:

– Елына ике тапкыр – язын-көзен сарыкларның йонын ала торган идек. Бу бер кеше генә башкара торган эш түгел, тирә-күрше хатыннары күмәкләшәбез дә баштан бер як күршенекен, аннан икенче якныкын алышабыз. Аннан шул йоннарны тетәбез. Кичен өй алды баскычына зур тукыма кисәге җәеп, аңа кичә алынган йонның бер өлешен салып, әбиләр, әниләр, балалар аякларын сузып, баскычка утырып, бисмиллаларын әйтеп, йон язалар. Кыска йоннарны – бер якка, озынракларын икенче якка куялар. Эше беткәч, артык кысмыйча гына, йон өеменнән төргәк ясап, аерым тукымага төреп куялар. Тик нишләптер, кара йонны өнәп бетермәде минем әни. Кер күтәрә, әмма җылылыгы юк, тиз туза, дия иде.

Хуҗабикә эш барышында үзенең кабасына бәйле тарихны да сөйләп бирде.

– Мин шушы авыл кызы һәм кияүгә дә монда чыктым. Бу кабаны миңа ирем Нурмөхаммәт юкә агачыннан ясап биргән иде. Ул заманда да бөтен гаиләгә, күрше-тирәләргә йон эрләдем. Әлеге каба миңа бик якын, яшьлегемнең, балаларымның әтисе белән яшәгән елларның якты бер истәлеге. Каба турында табышмаклар да бар. Шуларның берсе истә калган: «Кәкре әбием сәке өстендә утыра-утыра да, сәке астына кереп ята».

Йон эрләгәндә тагын бер мөһим эш коралы – ул орчык. Аны кипкән каен агачыннан ясаганнар. Ничәнче гасырда барлыкка килгәне дә билгеле түгел. Бүгенге көндә төрле бизәкле орчыклар табып була. «Минем орчык кайнанам истәлеге, – ди Әминә апа. – Монысы инде каба кебек зур түгел, ә уч табаныннан аз гына озынрак, уртасы юанрак, ике баш башы очлы таяк. Тик безнең әби орчык җенле ул, аның белән ялгыш та кешегә сугарга ярамый дип әйтә иде».

Әминә апа кабага йонны беркетте дә эрләргә кереште. «Йонны бер кул белән әкрен генә тартабыз, аннары орчык белән бөтереп барабыз», – дип кагыйдәләрен, нечкәлекләрен аңлатырга кереште.

– Бер көндә генә йон эрләргә өйрәнеп булмый, – диде Әминә апа. – Тырышлык, сабырлык сорый торган эш бу…

– Ә сез кемнән өйрәндегез? – дим.

– Әниемнән өйрәндем. Без дүрт бала – өч кыз, бер малай үстек. Әни барыбызга да күлмәкләрне үзе тегеп, бияләй-оекбашларны үзе бәйләп кидертте. Нинди авыр елларда да яланаяк, өс киемсез йөрмәдек.

Санаулы минутлар эчендә Әминә апа орчыкны тутырды. Ул арада алдан әзерләп куйган икенче орчыгын да чыгарды. Шулай итеп, ике орчыктагы җепләрне бер йомгакка чорнады. Мөгаен, иң җиңел эш шул булгандыр.

– Хәзер инде йомгактагы йонны янә орчыкка чорныйбыз – монысы кату дип атала, – диде Әминә апа.

Кату, ягъни җепне орчыкка чорнау да шактый катлаулы эш. Төп хикмәт – орчыкны тиз әйләндерергә кирәк.

Шулай да йоннан җеп әзерләүнең иң катлаулы эше дип, мин эрләү белән катуны саныйм. Катага бәйләнгән йонны тигез итеп тартырга кирәк: ул юан да, артык нечкә дә булмаска тиеш. Ә катканда, орчык белән эшләргә өйрәнергә кирәк. «Орчык белән дөрес идарә итмәсәң, җеп өзелә, җепне тигез итеп чорнарга өйрәнгәнче җиде кат тир түгәсең әле», – ди Әминә апа. Әйе, беренче тапкыр мондый эш коралы тоткан кешегә җиңел түгел. Ә менә Әминә апаның кулы кулга йокмый – эрләү машинасы диярсең!

Шулай итеп, ике орчыктагы җепләр бергә бәйләнде. Иң авыры тәгәлләнде



дияргә дә була, тик әле моның белән генә эш бетмәде…

Чиратта – орчыктагы җепләрне аякка чорнау. Дөрес, хуҗабикә аны кулга чорнады. Ә элек хатын-кызлар, аякларын бөкләп утырып, эрләнгән җепне тез башына чорнаганнар. Исеме дә шуннан калган – аякка чорнау.

– Аякка чорнаганда кеше булса, яхшы, – дип аңлата Әминә апа. – Берәү орчыкны әйләндерә, икенчесе җепне чорный. Без бәләкәй чакта әни, әбиләр безгә шулай җеп чорнаталар иде. Куллар арып бетә иде...

Җепләр орчыктан күчеп ярты метр тирәсендәге озынча түгәрәк формага әйләнде.

Чираттагы эш – җепне юу. Әминә апа моның өчен «кер сабыны» куллана икән:

– Сарык йоны бик майлы була. Кер сабыны белән югач мае да бетә, исе дә калмый, йоныбыз да кабарып, йомшарып китә, – ди ул.

Күбекле суда юып, ике өч тапкыр чайкап алганнан соң, җепләрне киптерергә куярга була. Ап-ак төскә керә алар. Җиңеләеп тә китә. Шуннан йомгакка чорныйсы гына кала.

Безнең халык йомгакка бигрәк иркәләп эндәшкән инде. Кайчак кечкенә генә, түгәрәк кенә, сары, йомшак.... Әминә апаның йомгагына да шундый берәр назлы сүз табасы килде – үзе ак, җепләре тигез… Оста куллы кеше, гомер буе эшләгәне күренеп тора!

– Булгач булсын инде, әйдә, бәйләп тә күрсәтәм. Сарык йоны оекбаш өчен әйбәт. Безнең балалар шундый оекбаш киеп үсте бит. Көннәр буе суыкта йөреп тә, аяклары туңмый иде, чөнки сарык йоны бик җылы. Бүгенге көндә кибеттә нинди генә носки юк, шулай да мин бәйлим – кучтәнәчкә дип тә бәйлим, кунакка да алып барам, – ди ул.

«Күңелемдә тагын бер хатирә яңарды. Элек авылда әбиләр сарык йонын тез башларына бәйләп куялар, язын кәзен галош төпләренә салалар иде. Болай эшләсәң, аяк сызлаулары басыла дия иде алар… Чыннан да авырткан җиргә кара сарык йонын бәйләп куйсаң, ярдәм итә. Мин дә шулай эшлим», – ди Әминә апа.

– Ак йон ярамыймы? – дим.

– Кара сарык йоны файдалырак, дип әйтәләр иде безгә әбиләр.

Сарык йонының файдасын мин дә сынап карарга киңәш итәм! Халык белми әйтмәс…

Автор фоторәсемнәре

*Евгения ШЕМЕЛОВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге методисты*

# ЕФӘКТӘГЕ *күңел бизәкләре*

СИХРИ, СЕРЛЕ, ГАҖӘЕП, ТЫЛСЫМЛЫ, ӘКИЯТИ – ТУКЫМА БИЗӘКЛӘҮ СӘНГАТЕН – БАТИКНЫ ШУЛАЙ ТАСВИРЛЫЙ АЛАБЫЗ. 2009 ЕЛДА ЮНЕСКО ПУМАЛА БЕЛӘН ТУКЫМА БИЗӘКЛӘҮ СӘНГАТЕН КЕШЕЛЕКНЕҢ РУХИ МИРАСЫ ШЕДЕВРЛАРЫ РӘТЕНӘ КЕРТТЕ.

РЕСПУБЛИКАДА БАТИК СӘНГАТЕНЕҢ ДӨНЬЯВИ ҮСЕШЕНӘ ҮЗ ӨЛЕШЕН КЕРТКӘН ОСТАЛАРЫБЫЗ БАР. ЯШЕЛ ҮЗӘН БАЛАЛАР СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕ УКЫТУЧЫСЫ, РОССИЯ ҺӘМ ТАТАРСТАН РӘССАМНАР БЕРЛЕКЛӘРЕ ӘГЪЗАСЫ ДИЛӘ БАРЫШЕВА – ШУНДЫЙЛАРНЫҢ БЕРСЕ.



Дилә ханым «батик» сүзе белән балачактан сихерләнүе турында сөйли. Әлбәттә, башта ул махсус белем алган – Яшел Үзән рәсем сәнгате мәктәбен һәм Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлаган. Батик ясау теләге шулкадәр зур булган ки – аны үзлегеннән өйрәнгән һәм камилләштергәннән камилләштерә барган. Шулай итеп, утыз ел дәвамында текстиль коллажлар, шарфлар, палантиннар, бизәкләнгән киемнәр – иҗатының аерылгысыз өлешенә әверелгән.

Дилә ханым тарафыннан ефәккә төшерелгән буяулар – төсле композицияләр генә түгел, илаһи атмосфера һәм тирән фәлсәфи мәгънә салынган картиналар. Ефәккә ясалган һәр бизәк – яктылык һәм матурлык чагылышы, уңай энергетика чыганагы.

Рәссам үз әсәрен иҗат иткәндә тукыма белән эшләүнең төп техникаларын куллана: салкын һәм кайнар батик, шулай ук, ирекле бизәкләү. Эш өчен бизәкләргә гаҗәеп нәфислек һәм җиңеллек бирә торган үтә күренмәле һәм нәзакатьле чын кытай ефәге алына.

Дилә Барышева Казанда, Чаллыда, Яшел Үзәндә, Алабугада, Йошкар-Олада, Германиянең Лосхайм шәһәрендә узган



«Йолдыз туганда»



«Ай тотылган төндә»



«Илаһи чәчәк»
«Болытларда уйнап» ▸





«Яз»



«Алар җырлый да»

дистәдән артык шәхси күргәзмә оештырган автор. Аларның һәркайсы шигъри исемнәре белән үк тамашачыны илаһи бер дөньяга әйди: «Ефәк юлламалар сәнгате», «Зәңгәр сәгать», «Җәйләр очты…».

Дилә Барышева өчен фольклор һәм сәнгать әсәрләре илһам чыганагы. Әйтик, «Яшерен мәгънәләр турында төшләр» триптихы XIII гасырда яшәгән күренекле фарсы суфи шагыйре Җәләлетдин Руми шигырьләре тәэсирендә туган.

Габдулла Тукайның «Кояш һәм ай» шигыре дә рәссамны иҗатка этәргән – кайнар

батик техникасында «Ай һәм кояш» картинасы ясалган.

Еш кына сюжетлар күргән матурлык, кичергән хисләр аша туа. Табигать тә илһамландыра. Гүзәл чәчәкләр ефәккә үзләре тамарга тора кебек.

Дилә ханымның иҗатында милли мотивлар торган саен ешая барганы күренә. «Үз мәдәниятең балачактан сеңә икән ул. Башта сизелмәгән кебек булса да, яши-яши син аны тоясың, күренмәс җепләр белән ул үзенә тарта, – дип аңлата Дилә Барышева. – Милли көйләрне, курай тавышын, татар биюләрен, гаҗәеп шигъри һәм образлы татар телен яратам».

«Батикта фантазиянең мөмкинлекләре чиксез – сез биредә шедеврлар иҗат итә торган рәссам. Биредә сәнгатьнең барлык юнәлешләре һәм стильләре сезнең карамакта! Сәнгати белемеңнең дәрәҗәсенә карамастан, батик белән шөгыльләнү шатлык китерә. Ефәк өстендә барлыкка килгән төсләр дөньясы серле бер тамаша булып күзләрне камаштыра, беркемне дә битараф калдырмый. Серен белмәгәннәр өчен бу – могҗиза, осталар өчен ләззәт», – ди рәссам.

Дилә Барышеваның эшләре Татарстан Республикасы Милли музеенда, Татарстан Дәүләт Сынлы сәнгать музеенда һәм шәхси коллекцияләрдә (Татарстан, Россия, АКШ, Германия, Польша, Венгрия) саклана.

Фоторәсемнәр Дилә Барышеваның шәхси архивыннан



**«Шәһәрчек»**



**«Күбәләк һәм чалма чәчәк»**



**«Синең чәчәкләр»**



**«Мадонна»**

*Филүзә МӘРДАНОВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең матди булмаган мәдәни мирас бүлеге мөдире*

# АЛМАЛЫ КӨЯНТӘСЕНӘ
## *кунмаган кош калмады*

ИДЕЛ ҺӘМ КАМА БУЕНЫҢ ЫЛЫСЛЫ ҺӘМ ЯФРАКЛЫ УРМАННАРГА БАЙ ТӨБӘГЕНДӘ ЯШӘГӘН ТАТАРЛАР ЭЛЕК-ЭЛЕКТӘН АГАЧ ЭШКӘРТҮ БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНГӘН. БИРЕДӘ ҮСКӘН АГАЧЛАРНЫҢ БАРЛЫК ТӨРЕ ДӘ ЙОРТ САЛУДА ЯКИ ХУҖАЛЫК ЭШЛӘРЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН, ҺӨНӘРЧЕЛЕК ӨЧЕН ЧИМАЛ БУЛЫП ТОРГАН.



**Фәйзулла Әминов рәсеме**

Татар балта осталары имән, каен, өрәңге кебек каты төрләрне дә, юкә, усак, нарат кебек җиңел һәм йомшак үзагачны да кулланганнар. Агач кәүсәсеннән, тузыннан, курысыннан, кайрысыннан, чыбыклардан, тамырыннан савыт-саба һәм башка хуҗалык кирәк-ярагы ясалган. Каеннан чүмеч һәм касә, кашык, декоратив чылбыр, ваза, ияр, өзәңге, дуга һәм камыт, көянтә, каба ясаганнар. Каенның кабырчыкланып торган кабы нәфис эшләнмәләр ясау өчен кулланылган. Ылыслы агачлардан чаңгы, көймә, арба һәм чананың кайбер өлешләрен эшләгәннәр.

Татарларның көнкүрешендә көянтә (көянтә – ике очында чиләк, яки башка авыр әйбер асу өчен ыргаклар куеп, яки уентылар уеп агачтан ясалган яссы дуга), дуга, чана табаны һәм тәгәрмәчнең агач тышлыгын бөгү кәсебе әһәмиятле урын алып торган. Чана табаны өчен каен, имән, карама кулланылса, көянтә өчен өрәңге, шомырт кулай булган. Чимал әзерләү өчен иң уңайлы чор – көз азагы яки яз башы. Нәкъ шул чакта үзагач сыгылучан була, димәк, көянтә өчен дуга ясарга менә дигән вакыт. Яхшы көянтә чыдам да, шул ук вакытта, җиңел дә, сыгылмалы да булырга тиеш.

Башкорт этнографиясен өйрәнүче галим З.С. Хәсәнова катай ыруы башкортларының көянтә ясау технологиясен кызыклы итеп тасвирлый. «Көянтә җитештерү барышында төп этапларның берсе – агач бөгү. Үзагачны йомшартып бөккәннәр. Катай ыруы башкортларының моның өчен руслардан күреп ясалган махсус пешекләү урыннары булган. Пешекләү бүлмәсе 100-120 чиләк су сыешлы казан куелган кирпеч мичтән һәм өч ниргәле парландыргыч бурадан торган. Парландыргыч сарайның диварлары һәм түшәме пар тышка чыкмаслык итеп җылытылган.

Инзер буенда яшәүче катай ыруы башкортлары традицияләрне бүген дә дәвам итә. Алар агачны йомшарту өчен буе 2 метрлы, диаметры 35-45 сантиметрлы металл торба куллана. Осталар бөгеләчәк агач борысны торба эченә тыгып, торбага 2-3 чиләк су салып кайнаталар: каен – 4 сәгать, имән – 5-6 сәгать, көянтә ясала торган шомырт агачы 15-20 минут кайнатыла. Парланган агачны махсус станга куялар. Ә стан дигәнебез өске ягы дугаланып торган агач түмәре. Бүгенге осталар традицион агач стан куллана, шундый ук формадагы металл станнар да була».

Татарларда да көянтә ясау процессы якынча шулай бара. Иң элек диаметры 8 сантиметрдан да ким булмаган метр ярымлы агач сайлап алына. Аны балта белән кирәк кадәр юнып юкарткач, кайнар суга салып парландыралар. Парланган агачны бөгүче җайланмага куялар. Әлеге җайланма борыслар белән тыгызлап беркетеп куелган калканны хәтерләтә. Көянтә бөгелешенә туры килеп торган борыс – үрнәк, туры читле борыс – терәк дип атала. Көянтә ясалачак агачны бөгүче җайланмага урнаштырганнан соң, терәк белән агач арасына ике яклап ике чөй кагып кертәләр. Чөй кагылганда агач эшләнмә бөгелеп үрнәк борыска ныграк терәлә. Берничә көннән эшләнмә кибеп, көянтәнең җилкәгә салынасы өлеше дугаланып килә. Көянтәне кирәкле радиуска кадәр бау тарттырып та бөгергә була. Аннары көянтә очларына шөрепләр белән металл элгечләр беркетеп куялар – болары чиләк элү өчен. Әзер көянтәне тәрәзә пыяласы кисәкләре белән ышкып эшкәртәләр, наждак кәгазе белән шомарталар, буйыйлар, бизәклиләр. Ярылмасын өчен өстенә калай да кагыла.

Өлкән буын сүзләренә караганда, көянтә аерым очракларда 50 елга кадәр һәм аннан да күбрәк хезмәт иткән. Хуҗалыкта ул махсус кагылган чөйгә эленеп куелган.

Хәзерге вакытта көянтәләрне Татарстанда «Ива мебель» фабрикасы ясый. Ул Балтач районының Янгул авылында урнашкан. Фабрика 2012 елдан бирле үз җирлегендә традицион һөнәрчелекне торгызу белән шөгыльләнә. «Ива мебель» көянтәләрне талдан бөгә. Бер көянтәнең бәясе 1000 сум тирәсе. Осталар әйтүенчә, алар елына 100-200 көянтә ясый ала. Әмма ихтыяҗ зур түгел.

Беренче карашка, көянтә авыр әйберләрне күчерү өчен хезмәт итә торган гап-гади җайланма. Ә бит уйлап карасаң, ул татар халкы йолаларының бик кирәкле бер атрибуты. Мәсәлән, татарларда «су юлы күрсәтү» йоласы бар. Туй көнендә яшь килен көянтә-чиләк белән суга барырга һәм тамчысын да түкмичә су алып кайтырга

тиеш. Авыл халкы киленнең судан кайтуын күзәтергә чыга – шулай итеп аның уңганлыгын бәяли.

Сабантуйда иң матур ярышларның берсе – көянтә-чиләк белән су ташу. Катнашучылар суны түкмичә финишка килеп җитәргә тиеш. Чиләгендә суы күбрәк булып, финишка иң беренче килеп җитә алган кеше – җиңүче. Бу уен билгеле бер тәҗрибә таләп итә, чөнки көянтәне беренче тапкыр иңенә куйган кеше җиңүгә өметләнә алмый.

Татар халкында көянтәгә бәйле ышанулар да бар. Менә аларның кайберләре – Арча районы Өчиле авылында язып алынганнары:

– Көянтә аша атлап узсаң, көзән җыера.

– Мал-туарны көянтә белән кыйнасаң, көянтә кебек кәкре балалар туа.

– Юлда буш чиләкле хатын очраса – юлың уңмый, чиләкләре тулы булса – юлың уңа.

– Җомга көнне тәһарәт вакытында чишмәгә суга төшәргә ярамый, ул вакытта фәрештәләр су ала.

Хәзерге вакытта татарларда көянтә ясау һөнәре дә, ясау технологиясе дә югалып бара. Көнкүрештә берничә дистә ел элек ясалган көянтәләр кулланыла. Бүгенге көндә көянтәләрне хуҗалыкта кулланырга дип түгел, ә фольклор һәм театр коллективлары өчен җитештерәләр.

**Чыганаклар:**
1. Брусько З.М., Завгарова Ф.Х. В круге жизни. – Казань: Ихлас, 2013. – 224 с.
2. Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.У. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. – М.: Советский художник, 1990. – 210 с.
3. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: 3 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959-1967.
4. Сабантуй: методическое пособие / Под ред. Ф.Х. Завгаровой. – Казань, 2012. – 76 с.
5. Хасанова З.Ф. Домашние производства из дерева у башкир Инзерского бассейна // Ватандаш. – 2017. – С. 174-193.



**Борынгы көянтәләр. https://cache3.youla.io/files/images/780_780/5d/fa/5dfa3523e7696a6439239578.jpg**



Кукмарада Сабантуй. Эльвира Мөбарәкшина фоторәсеме

# Тәчкә-икә

*Татар халык җыры*

*Чибәр кызлар суга бара*
*Чиләк-көянтә асып.*
*Сандугачлар кунып сайрый*
*Көянтәсенә басып.*

***Кушымта:***
*Тәчкә-икә, икә, икә, икә, икә, икәкәй.*
*Сандугачлар кунып сайрый*
*Көянтәсенә басып.*
*Тула микән, тула микән,*
*Тула микән чиләге.*
*Чиләгенә карагандa*
*Үзе кура җиләге.*

*Кем җанкае суга бара*
*Шәл яулыгын ябынып?!*
*Шәл астыннан качып карый*
*Күрмәмешкә салынып.*

*Тәчкә-икә, икә, икә, икә, икә, икәкәй.*
*Шәл астыннан качып карый*
*Күрмәмешкә салынып.*
*Тула микән, тула микән,*
*Тула микән чиләге.*
*Чиләгенә карагандa*
*Үзе кура җиләге.*

*Барма, җаныем, су читенә*
*Су чәчерәр битеңә.*
*Исемеңне чигеп бирче*
*Кулъяулыгың читенә.*

*Тәчкә-икә, икә, икә, икә, икә, икәкәй.*
*Исемеңне чигеп бирче*
*Кулъяулыгың читенә.*
*Тула микән, тула микән,*
*Тула микән чиләге.*
*Чиләгенә карагандa*
*Үзе кура җиләге.*

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм*
*сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге*
*баш фәнни хезмәткәре*

# ТАТАР ТАРИХЫ – *халык иҗатында*

(КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫНА КАРАГАН ТАРИХИ ҖЫРЛАР, ХУШАВАЗ ҺӘМ БӘЕТЛӘР МИСАЛЫНДА)

Татар фольклор истәлекләре арасында Казан ханлыгы тарихына нисбәтле тарихи җырлар, халык җырларының үзенчәлекле төркемен тәшкил итә торган хушавазлар, сүз сәнгатенең лиро-эпик төренә караган бәетләр аерым урын алып тора.

Бу чорга караган тарихи җырларның тематикасы артык киң дип әйтеп булмый. Татар тарихи җырларының фәкать кайберләре генә безнең көннәргә килеп җитә алган. Алар – халык тормышында булган тетрәндергеч вакыйгаларга багышланган берничә бөртек әсәрдән гыйбарәт ядкярләр. Тарихи җыр төренә караган истәлекләрнең аз санда булуын үз вакытында бу әсәрләрне язуга теркәүнең башкарылмавы, тора-бара ул үрнәкләрнең халык хәтереннән бөтенләй юылуына бәйле аңлатырга мөмкин. Тарихи җырларның эчтәлек ягыннан җитдилеге, сюжеты, мотивлары, композициясенең җыр жанрының лирик төренә караганда күпкә катлаулырак булуы да аларны барлау-өйрәнүдә кайбер кыенлыклар китереп чыгарган. Шул ук вакытта татар тарихын барлаганда һәм торгызганда тарихи җырларның әһәмияте әйтеп бетергесез.

Жанр төре буларак чагыштырмача мөстәкыйльлек саклап, бүгенге көннәргә килеп җиткән тарихи җырлар арасында Сөембикә ханбикәгә, аның Казан белән хушлашуына, туган иленнән Идел буйлап читкә озатылуына багышланган «Сөембикә китеп бара», «Тоткын Сөембикә җыруы» кебек тарихи җырлар игътибарны җәлеп итә.

«Сөембикә китеп бара» дип аталган тарихи җырда тарихи вакыйгалар урын алу белән бергә төрки эпос традициясеннән килә торган елау-сыктау мотивы чагылыш тапкан. Эпос-дастаннарда ананың баласын югалткач елавына, батыр белән хушлашканда сөйгәненең сыктавына киң урын бирелсә, биредә Сөембикәнең иленнән аерылган чактагы әрнүе сурәтләнә. Монда Казан ханлыгы чоры халык авыз иҗатына хас символик образларга, мәсәлән, ак яулык, ут көймәсе, хәсрәттән иелгән баш һәм башкаларга да тап булабыз:

*Идел ага яр кагып,*
*Уңга-сулга чайкалып;*
*Ут көймәсе китеп бара*
*Сөембикәне алып.*
*Сөембикә ак яулыгын*
*Тоткан учлап кулына;*
*«Хуш, Казаным, каласың», – дип,*
*Үкереп елый буена.*
*Ия башын, түгә яшен,*
*Казанга таба карап;*



**Чыңгыз Әхмәров. «Борынгы фреска»**

*Миннән башка ничек итеп*
*Көн итәрсез дип аяп.*

Сөембикәгә багышланган тагын бер тарихи җыр төрки эпостан килә торган тулгау, сыктау, сарын кебек эпик җыр традицияләрен саклаган. «Тоткын Сөембикә җыруы» дип аталган бу җырда ханбикәнең тоткынлыкка кадәрге тормышы сурәтләнә:

*Кая китте яшь вакытым,*
*Назлы үскән чакларым;*
*Йөз мең алтын торыр иде*
*Бәнем атланган атым.*
*Чыга торган идем аугa*
*Башыма таҗлар киеп;*
*Инде таҗ урынына калды*
*Бу озын кара сачем.*
*Чорнала иде як-ягым*
*Кәнизәк кызлар белән;*
*Һәрвакытта да баш вәзир*
*Янымда иде юлдашым.*
*Алтыннар илә бизәлгән*
*Иде бәнем тәхетем,*
*Инде тәхетем улды хәзер*
*Шушы утлырган ташым.*

Эчтәлеге һәм эмоциональ яңгырашы ягыннан гаҗәп тәэсирле бу җыр халык арасында гаять популярлыгы белән дә үзенчәлекле. Ул – татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә үз вакытында шактый еш очраган лиро-эпик иҗат үрнәкләренең берсе. Җырның фольклористикада мәгълүм вариантлары Татарстанның төрле районнарында язып алынган, шулай ук Башкортстан Республикасына, Түбән Новгород, Ульян (Сембер), Чиләбе, Свердловск, Пенза өлкәсенә караган татар авылларында яшәгән информантлар авызыннан теркәлгән яисә кулъязма дәфтәрдән күчереп алынган. Әлеге тарихи җырның һәрбер үрнәге эпик җыр төренә хас тулгау-сыктау мотивына корылган, алар Сөембикә-ханбикә һәм ил язмышын характерлыйлар.

Үзенең эчтәлеге һәм төп идеясе белән «Тоткын Сөембикә җыруы»на бик якын истәлек – «Кунак бабай җыруы»:

*Йөз туксан биш яшь яшәдем,*
*Азу тешләрем ашадым,*
*Күпне күреп, күпне белеп,*
*Гомер сөргән карт мин.*
*Иделдә үтте тугыз хан,*
*Җаекта үтте сигез хан;*
*Шул ханнарның барысын да*
*Күреп белгән карт мин.*
*Илне йоткан Туймас хан,*
*Юмарт булган Исәк хан;*
*Берсен сүгеп, берсен мактап*
*Күп җырлаган карт мин.*
*Энҗү дәрьяң киң дәрьядыр,*
*Бәнгиз дәрьяң мул дәрьядыр,*
*Мактыйм дисәм, телем йөрми –*
*Туры сүзле карт мин.*
*Туып үскән, суын эчкән,*
*Идел белән Җаегыма*
*Кайтарсагыз ни булган, дип,*
*Башым игән карт мин.*
*Идел белән Җаегымда*
*Ярлы-ябага илкәем,*
*Үлә калсам, ак тәнемне*
*Күмәр, дигән карт мин.*

Бу җырда да Казан ханлыгы чоры вакыйгалары һәм тоткынлык зары чагылыш тапкан. Новосибирск өлкәсендә язып алынган әлеге ядкярдә «Идегәй» дастаныннан һәм тагын да борынгырак эпик тамырлардан ук килә торган җырау образына юлыгабыз, җырда чичән-җырау ил-көнгә кагыла торган мөһим мәсьәләләрне, тарихи шәхесләрне телгә ала, туган иленә – Идел белән Җаекка – карата җирсү хисләрен белдерә, халыкка изге теләкләрен җиткерә.

Татар ханлыкларының бердәмлегенә, Казан һәм башка татар ханлыкларының үзара мөнәсәбәтләренә ишарә итүгә корылган кайбер хушаваз җырларын да татарларның борынгы тарихын чагылдыра торган халык иҗаты әсәре буларак карарга тулы нигез бар. Әйтик, Әстерхан өлкәсе Идел буе районы Татар Башмагы авылында язып алынган «Астырханга, Астырханга Казан яктан су килә» дип исемләнгән хушаваздан китерелгән өзектә әлеге Казан–Әстерхан тарихи бергәлеге чагылыш тапкан:

*«Астырханга, Астырханга*
*Казан яктан су килә,*
*Астырханга, Астырханга,*
*Казан яктан су килә,*
*Казан яктан су килә лә,*



**В.Г. Худяков. «Казанны ташлап китеп баручы әсир Сөембикә», 1870**

*Казан яктан су килә.*
*Сал өстендә килеп туктый*
*Астырханның мостына...»*

Әлбәттә, телгә алынган тарихи җырлар һәм хушавазлар гына түгел, җыр жанрының башка төркеменә керә торган куплегән гүзәл лирик әсәрләр – татар халкының озын көйгә лирик җыр үрнәкләре, кыска дүртьюллыклар, йола җырлары, уен-бию җыр-такмаклары – барысы да татарларга Казан ханлыгы чорыннан ук, ә бәлки, тагын да элегрәк билгеле булганлыгы аңлашыла. Шуңа күрә мәгълүм бер чорга караган иҗат дигәндә югарыда саналганнар белән чикләнү шактый шартлы булуны һәрвакыт истә тоту дөрес булыр. Биредә игътибар реаль вакыйгалар, җирле топонимика яисә чынбарлыкта яшәп, эшчәнлек алып барган шәхесләр телгә алынган тарихи җыр текстларына һәм хушавазларга гына бирелде.

Казан ханлыгы чоры вакыйгаларын безнең көннәргә китереп җиткергән халык иҗаты әсәрләре арасында лиро-эпик жанрга карый торган бәетләр үзләренең эчтәлеге, төп мотивлары, шигъри эшләнеше белән тарихи җырларга бик якын тора. Жанр атамаларындагы синкретиклык, әйтик, «Казан бәете»н тарихи җыр дип атауга да нигез булып тора. Бу әсәрдә тарихи чынбарлыктан шактый читкә киткән мәгълүматлар белән бергә реаль вакыйгалар һәм шәхесләр телгә алына, Казан ханлыгының кайсы хан вакытында нинди тормыш белән яшәвенә бәя бирелә, Казан алыну вакыйгасында чынлыкта катнашкан һәм катнашмаган шәхесләр мактала, Казанның бәйсезлеге идеясе үзәккә алына.

Бу бәеткә киңрәк тукталып, аның Болгар чорыннан алып Казан алыну вакыйгаларынача татар халкы тарихын кыскача яктыртуын искәртик. Бәеттә Аксак Тимернең Габдулла хан кулыннан Болгар шәһәрен алуы турында сөйләнә. Шуннан сүз Казан ханлыгына күчә. 262 ел буе Казанның мөселманнар кулында булып, аннары урыслар тарафыннан яулануын хәбәр иткәннең соңында, әсәр Казан алынганчы андагы тормыш-көнкүрешне тасвирлый. Тасвир ханнар идарә иткән чорга мөнәсәбәттә хронологик төстә бара.

Газыйлары (дошман белән сугышучылары) күп иде, муллалары күп иде,

Галимнәре күп иде заман Ядкарь (Казанның соңгы ханы) ирдия

Бу җиһан мөнәүвар (якты, нурлы) иде, җәбер вә җәфа юк иде,

Мөрид (шәкерт) – мөршид (туры юл күрсәтүче) күп иде, заманы хуп ирдия.

Галимнәре дус иде, мөршидләре хасс (биредә: җәмгыятьнең югары катлавы) иде

Барча дошман пәст (түбән, хурлыклы) иде, заманы Ядкарь ирдия.

Ядкарь хан бәеттә күккә чөеп мактала. Казан шәһәре урыслар тарафыннан яуланган чорда Касыйм хан углы Ядкарьнең хан булып утыруы мәгълүм. Ул Казанда озак патшалык итмәгән (1552 елның марты – 1552 елның октябре), тарихта җитди эз калдырмаган. Тарихи чыганаклар күрсәтүенчә, Иван IV Казанны алган вакытта Ядкарь хан урысларга әсир төшә, үлгән елы билгесез, әмма 1553 елда ул әле исән була. Бәеттә Ядкарь ханның «тугыз йөз илле җидедә» дөньядан китүе әйтелә. (Милади белән 1550 елга туры килә.) Бу – тарихи вакыйгаларның халык иҗатында буталып бирелүе, фольклорга хас контаминация нәтиҗәсе. Алга таба әсәр Ядкарьнең бик булдыклы бер кызы калуын хәбәр итә. Имеш, атасы аны тәхет варисы итеп калдырган. Әмма атасы үлеп киткәч, ни сәбәпледер, кыз үзен-үзе үтерә. Бәет жанрында игътибарны аянычлы вакыйгаларга күбрәк бирү хас, әлеге мотив әсәргә шушы максатлардан кертелгән булырга тиеш. Документаль яктан расланмаса да, хан кызы халык иҗатында популярлык тапкан, бер жанрдан икенчесенә күчеп яшәүче уртак образга әверелгән.

Шаһгали хан образы бәеттә Шагали дип бирелә:

*Нәселендә бер ир бар ирде,*
*исеме аның Шагали*
*Шифаларга яр ирде,*
*тоткын булмыш ирдия.*

Аңа бәеттә тискәре мөнәсәбәт сизелә:

*Дөнья дигән сарайга*
*җәбер-җафа салдыя.*

Бәеттә Казанның урыслар тарафыннан яулануында Шагали гаепләнә. Монда тарихи шәхес Шаһгали ханга гади халыкның мөнәсәбәте ачык чагыла. Бәеттә ханнарның хронологик тәртибе үзгәртеп бирелгән. Шаһгалинең Казан тәхетендә соңгы тапкыр 1551-1552 елларда, ә Ядкарьнең аннан соң утыруы мәгълүм. Чорның гомуми атмосферасы исә бәеттә дөрес чагылыш тапкан. Монда Казан–Мәскәү арасында XVI йөз урталарына таба даими булып торган орышкөрәш картинасын күрергә мөмкин.

*Урыслар хәбәрдар ые,*
*мөселманнар бихәбәр ие,*
*Шәһри Казан җанында*
*орыш-тукыш булдыя.*
*Ул орыштан булмады,*
*Казан шәһәрен алмады*
*Ошбу Зөя тавында урыс кала салдыя.*

Мөселманнарның Иван IV кылган бу гамәл белән килешмичә, ризасызлык белдереп, урыслар белән сугыша башлавы турында бәетнең алдагы 2 юлы хәбәр итә. Аннан соң текстка Чура батыр исеме килеп керә:

*Бар иде бер мәрди (биредә: батыр, кыю мәгънәсендә) Хода, исеме аның Чура*
*Күп урысны кырырга Ходай мәдәд (ярдәм, булышлык) бирде йа.*

Билгеле булганча, Чура батыр образы татар халык иҗатының башка күп кенә жанрларында да очрый. Аларның барысына хас булганча, бәеттә дә Чура – ханлыкта атаклы пәһлеван, курку белмәс батыр, азатлык өчен көрәшкә күтәрелгән шәхес. Бәеткә Чура образы иң киеренке урында килеп керә, аның эш-гамәлләренә киң урын бирелә, Чура үзе идеаллаштырыла, хәтта Алла бәндәсе итеп күрсәтелә. Бәеттә ачыктан-ачык ислам идеяләре уздырылган. Чура – Казан халкы өчен бердәнбер өмет, шуңа да авыр минутта халык аңа мөрәҗәгать итә:

*Диделәр аңар, җә, Чура,*
*булырсың мәрди Хода,*
*Алланың хөкеменә нидер чара?*
*Ибан урысны син тура.*

Алга таба Чура урыс патшасына килеп, аның чатырына үтеп керә, патшаның

башын чабып өзә. Бу вакытта дошман патшасы ашап утыра торган була, өзелгән башы ашына килеп төшә. Алдарак бәеттә урысларның күп, көчләре җитәрлек булуы әйтелгән иде. Патшаның үлемен артык самимиләштерүгә аклангандай, я булмаса, урыс патшасын каралтыбрак күрсәтер өченме, бәеттә түбәндәге юллар китерелә:

*Акылы җуктыр башында, күп халкы бар кашында*
*Ник боермады бер башына: ыстрог торың каршымда (ягъни строго тор, яхшы сакла мәгънәсендә).*

Чураның батырлыгын, урыс патшасының үлемен тасвир иткәннән соң, бәет, жанрга хас булганча, чын мәгънәсендә фаҗигале вакыйгага күчә – Казанны урыс явы басып алу турында сөйли.

«Сөембикә бәете»ндә исә ханбикә тормышы сурәтләнә, тасвир бәет жанрына хас булганча, үлгән кеше авызыннан, ягъни Сөембикә ханбикә исеменнән алып барыла, Сөембикә шигъри формада үзенең туганнан алып ни рәвешле үсүен, Җангалигә кияүгә бирелеп, Казанга килүен һәм ханлыкта аннан соңгы вакыйгалар хакында бәян итә. Бәеттә ханбикәнең тоткынлыкка төшүе Казанның хәлендә үтә тискәре чагылыш тапканлыгы турында әйтелә. Бәет ахырында:

*Дөньяга килгән адәм кайгы күрмичә тормый,*
*Дөньяда шат йөргәннең дә туфрак тыр ахыр урыны, –*

дигән сүзләр белән зур вакыйгаларга исламча гомуми нәтиҗә ясала.

«Казан бәете» дә, «Сөембикә» бәете дә фаҗигалелеккә корылган булуы белән үзенчәлекле, шулай ук әсәр стилендә бәет жанрына хас булган сәнгати алымнарга өстенлек бирелү дә аларны аерым жанрда карарга мөмкинлек бирә.

Казан ханлыгы составына хәзерге татарлар яши торган бик күп төбәкләр кергән: Сембер, Пенза, Тамбов өлкәләре, Чувашстан, Мари, Удмурт, Мордва республикалары җирләре, Нижгар, Сарытау, Самара, Пермь өлкәләренең өлешләре, бүгенге көнбатыш Башкортстан җирләре – болар бар да Казан ханлыгы җирләре, элек-электән татарлар төпләнеп яшәгән урыннар. Казан ханлыгына чаклы да бу һәм башка урыннарда татарларның тарихи ватаны булганлыгы мәгълүм. Әлеге шартлар популяр җыр-бәетләрнең һич каршылыксыз татарлар яшәгән күп төбәкләргә таралуын тәэмин иткән. Югарыда телгә алынган фольклор ядкярләре татарлар компактлы яши торган төрле төбәкләрдә, Татарстан авылларыннан алып Россия Федерациясе өлкәләрендә авыл-авыл булып яшәүче милләттәшләребездән язып алынган, кулъязмаларда табылган яисә язуга күчерелеп, архивларга тапшырылган. Бүгенге көндә дә, әйтик, Әстерхан өлкәсендә яшәүче милләттәшләребездә популяр хушаваз җырларын Татарстан авылларында яисә Н.Ф. Катановның «Исторические песни Казанских татар» исемле китабында (Катанов Н. Ф. Исторические песни Казанских татар. Казань, 1899. С. 5-22) дөнья күргән әсәрләрдәге (әйтик, «Казан бәете» шушы чыганактан алынды) сюжет һәм образларны татарлар яши торган төрле төбәкләрдә табылган риваять, дастан кыйпылчыкларында очратабыз икән, бу – тамырлар берлегенә дәлил.

Казан ханлыгы чорына караган теге яки бу фольклор әсәрләрнең вариантлары, өзек-төтек хәлдә булса да, татарлар яши торган төрле төбәкләрдә әле дә очрап куя. Белемле, зыялы, динле халкыбыз укырга яраткан, маҗара, тамаша яраткан, шуңа да, кая гына яшәсә дә, үз халкының авыз иҗаты әсәрләрен бишектән үк ишетеп үскән. Татар халык иҗатының Казан ханлыгы чорына багышланган фольклор ядкярләреннән югарыда телгә алынган җыр, хушаваз, бәетләр асылда татар милләтенең борынгы төрки тамырларын, тарихи үткән юлын барлауда, халыкның таралыш ареалын билгеләүдә катнаша, халыкның күп гасырлык борчу-мәшәкатьләрен, шатлык-куанычларын, дөньяны аңлау-аңлатуда карашларын чагылдыра, Казанның үз батырлары булуын, милләтнең ныклы тамырларын ассызыклый, милли-мәдәни үзбилгеләнүне тәэмин итүдә әһәмиятле роль башкара.

*Әңгәмәдәш –*
*Рәзинә ИСМӘГЫЙЛЕВА*

# Җырлы гомер

ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН МӘДӘНИЯТ ХЕЗМӘТКӘРЕ, КОМПОЗИТОР, АВТОР-БАШКАРУЧЫ, ҖЫРЛАР, МӨНӘҖӘТЛӘР, БӘЕТЛӘР АВТОРЫ, БИК КҮП ЕЛЛАР ЧАЛЛЫДА ЯШӘП ИҖАТ ИТКӘН ХЕЗМӘТ ВЕТЕРАНЫ ГӨЛСИНӘ САБИРОВА – РЕДАКЦИЯБЕЗ КУНАГЫ.

**Гөлсинә ханым данлыклы Саба якларында, Төбәк авылында Афзалниса белән Хуҗахан Бахмановларның 7 балалы ишле гаиләсендә туып үсә. Авыл мәктәбендә 8 нчене, Икшермәдә 10 нче сыйныфны тәмамлап, Әлмәт шәһәрен яуларга китә: 18 яшеннән һөнәр үзләштереп, токарь булып эшли. Әмма балачактан җыр-моңга гашыйк Гөлсинә 21 яшендә Алабуга культура-агарту көллиятенә укырга керә. Аны тәмамлагач, ул Мамадыш районының Олыяз авылы Мәдәният йортында художество җитәкчесе булып эшли һәм авылның балалар бакчасында җыр дәресләре алып бара. Балачагы, Чаллы якларына китүе, ничек җыр сәнгатен сайлавы турында Гөлсинә ханым болай сөйли:**

– Әнием Афзалниса бик моңлы иде. Казанда ФЗӨда тегүчелеккә укыганда Фәйзи Биккинин да «Уракчы кыз» җырын минем әнидән җырлаткан. Әни Гөлсем Сөләйманова, Оркыя Ибраһимова белән бергә җырлап йөргән. Филармониягә дә чакырганнар үзен, әмма укыган җиреннән документларын бирмәгәннәр. Әтием Хуҗахан да җор телле, такмаклар әйтергә ярата иде.

Күгәрченнәр гөрләшәләр,
Зәңгәр өй төбәсендә.
Мин дә өмет итеп йөрим,
Тәрәзә тирәсендә, – дип җырлаганы хәтердә калган. Әти белән әнине бер мәҗлестән дә калдырмыйлар һәм безнең өйдә дә кунаклар еш була иде, без – бала-чага аларны чаршау артыннан гына тыңлап утыра идек.

Ә Чаллы – минем яшьлегем узган шәһәр. Чаллыга мин, стена радиосы аша дүрт тавышка җырлаган җырларын ишетеп, «Ләйсән» вокаль ансамблен эзләп килдем. Таптым. Ул шәһәрнең «Энергетик» Мәдәният сараенда оештырылган иде. Һәм шушы гүзәл ансамбльдә минем җыр-моң сәнгатендә иҗат юлым башланды. Хезмәт юлымның 28 елы да шушы ук Мәдәният йорты белән бәйле, мин аның белән горурланам. Чөнки шушы еллар эчендә бик күп үзешчән сәнгать артистлары, бүгенге көндә исемнәре танылган – Илгиз Закиров, Азат Тимершәех, Шәфәгать Салихов, Фәрит Әхсәнов, Флера Хөрмәтова, Клара Бакинская, Нурия Хәйруллина кебек композиторлар, җырчылар, музыкантлар белән кулга кул тотынып эшләргә, иҗат итәргә туры килде. Чаллыда ул елларда бездән башка бер генә чара да, бәйрәм дә, хәтта кечке уеннар – «пятачоклар» да үтми иде. Әлбәттә, барыбызны да җитәкләп йөрүче Гөлзада Рзаева булды. Үзешчән сәнгатькә зур өлеш керткәнем өчен күкрәгемне 3 медаль бизи.

**– Гөлсинә ханым, сезне Илгиз Закировның «Бар ул син эзләгән кеше», «Саубуллашу», «Моңлану» кебек иң беренче язган җырларын башкаруыгызны беләбез. Үз җырларыгызны кайсы чордарак иҗат итә башладыгыз?**





– Кызым тугач, мине сагышлы да, татлы да бер моң биләп алды. Кичләрен сабыемны йоклатканда эчемнән генә көйлим: «Әллии-бәллии»... «Бишек җыры»м шулай туды. Шул көннән башлап, иҗатым бүгенгәчә туктаганы юк. Җырларымны башкаручылар арасында Хәмдүнә Тимергалиева («Эх, дөньясы»), Салават Фәтхетдинов («Бәхетләрне ерактан эзләмә»), Зәйнәп Фәрхетдинова («Сабыр бул», «Аваз салам галәмнәрдән»), Хәния Фәрхи («Аңламадың», «Мингәр гимны»), Резеда Шәрәфиева («Кичер әни», «Аерыласым килми», «Язмышым серләре»), Равил Галиев («Әлләниләр уйлама әни», «Син бер моң, мин бер моң», «Дусларыма шатлык өләшәм»), Азат Тимершәех («Сабантуй», «Гаилә җылысы»), Ришат Шәйхетдинов («Әти») һәм башка күп кенә җырчыларыбыз бар.

**– Сезнең язмыш Казан белән дә бәйле Гөлсинә ханым... Сез бирдә, кайда хезмәт куйдыгыз?**

– Төрле җыр бәйгеләреннән танып белгән композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М. Җәлил исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, күп санлы популяр җырлар авторы Риф Гатауллин мине Бауман урамында урнашкан Халык иҗат йортына белгеч буларак эшкә алды. 2007 ел иде ул. Лаеклы ялга да мин шуннан чыктым. 55 яшьлек юбилеем уңаеннан оештырылган иҗат кичәм дә Казанда, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә үтте. Шул елларда Хәмдүнә Тимергалиева төркемендә дә эшләдем. Татарстан, Россия буйлап гастрольләрдә йөрдек аның белән. Мин алып баручы, автор-башкаручы булып үз җырларымны башкара идем. Ялга чыккач та эшләвемне дәвам иттем: Казандагы 78 нче мәктәптә «Шатлык» фольклор балалар төркеме оештырдым. Алар белән төрле бәйгеләрдә катнаштык, сәхнәләрдә татар халкының йолаларын, гореф-гадәтләрен яктырткан сценарийларны куйдык.

**– Бүгенге көндә нинди хыяллар белән яшисез, Гөлсинә ханым? Күреп, ишетеп торам, иҗат итәсез, җырларыгыз әле радиода, әле сәхнәләрдә яңгырап тора...**

– Халык яратып тыңлый торган – «Аерыласым килми», «Салкын Алан», «Көзге урман», «Кичер әни», «Төбәгемне сагынганда», «Язмышым серләре», «Тан-







го Сабада», «Әти», «Сабантуй» «Яшьлек язым», «Дүрт Мунча», «Яңа Арыш», «Син бер моң», «Чаллы җире», «Әлләниләр уйлама әни» кебек җырларым, чыннан да, сәхнәләрдә әледән әле яңгырап тора. Туган авылым – Төбәктә «Авылдашлар очрашуында», Сабантуйларда, кичке Сабантуйларында катнашам. 2017 елда клуб житәкчесе белән фольклор ансамбль оештырдык. Хәзер ансамбль бик күп чараларда катнаша, һәр бәйрәмнең бизәге булып тора.

Кеше өчен иң кыйммәтле байлык ул – рухи байлык, күңел байлыгы. Соңгы елларда мин дә рухи ныклык, байлык туплыйм – дини гыйлем үзләштерә башладым – Мөхәммәдия мәдрәсәсендә белем алам. Туган авылымдагы туган нигезне сакларга, туганлык җепләрен өзмәскә, кызыма гореф-гадәтләрне, йолаларыбызны биреп калдырырга тырышам.

Кызым Гүзәлнең уңышларына сөенү, концерт-кичәләремдә тамашачымның мине яратуын, хөрмәт итүен тою, көн саен район радиосыннан үзем язган «Дулкын» гимнын ишетү – болар барысы да минем күңелемә шифа. Җырлы гомер биргән Аллаһыма мең шөкер!



Фоторәсемнәр Гөлсинә Сабированың шәхси архивыннан



Аманулла. «Ташлап китмә...» мелодрамасы

*Әңгәмәдәш –*
*Рузилә МӨХӘММӘТОВА*

# Калфагын җуймаган ТЕАТР

СЕНТЯБРЬ АЕНДА КАМА ТАМАГЫ РАЙОНЫ ОЛЫ КАРИЛЕ АВЫЛЫНДА МИНЗӘЛӘ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ТЕАТРЫНА НИГЕЗ САЛЫП, АНЫ 30 ЕЛДАН АРТЫК ҖИТӘКЛӘГӘН САБИР ӨМЕТБАЕВ ХӨРМӘТЕНӘ БЮСТ АЧЫЛДЫ. БЮСТНЫ РЕЖИССЕРНЫҢ ТУГАН АВЫЛЫНА ТЕАТРНЫҢ ХӘЗЕРГЕ КОЛЛЕКТИВЫ БҮЛӘК ИТТЕ. «БЕЗНЕҢ ӨЧЕН МОНДА КИЛЕП БЮСТ АЧУ БИК МӨҺИМ, ЧӨНКИ САБИР ӨМЕТБАЕВНЫҢ ТАТАР ТЕАТРЫ ТАРИХЫНА КЕРТКӘН ӨЛЕШЕ БӘЯЛӘП БЕТЕРГЕСЕЗ. АВЫЛ ХАЛКЫ ҮЗЕНЕҢ БӨЕК УЛЫН БЕЛӘ ҺӘМ ХӘТЕРЕНДӘ ТОТА, БУ БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ЗУР ШАТЛЫК», – ДИДЕ ТЕАТР ДИРЕКТОРЫ ИЛНУР ГАЙНИЕВ ТАНТАНАДА.

Минзәлә театрының легендар шәхесләре белән бәйле икенче яңалык – Минзәлә шәһәрендә Татарстанның халык артистлары Илүсә һәм Фәез Бәдриевлар, Татарстанның халык артисты Рөстәм Муллин яшәгән йортларга күренекле шәхесләр хөрмәтенә истәлек такталары куелды.

Болар театрның 85 еллыгы уңаеннан эшләнгән эшләрнең кайберләре – театр тарихына кагылышлылары, театрның легендар шәхесләре исемнәрен мәңгеләштерүче гамәлләр.

## ТАРИХИ СӘХИФӘЛӘР

1930 елда Татарстан мәгариф халык комиссариаты каршында Культура штабы төзелә, аның рәисе итеп драматург Риза Ишморат билгеләнә. Бу чорда даими эшләүче колхоз-совхоз театрлары кирәклеге көн үзәгенә куела.

Татнаркомпрос карары буенча 1934 елда Чистай шәһәрендә беренче номерлы колхоз-совхоз театры төзелә. Аның башлангычында 1922 елда Г. Гайсин җитәкчелегендә оештырылган һәвәскәр коллектив (түгәрәк) тора. 1936 елның апрелендә, колхоз-совхоз театрлары челтәрен республикада тигез җәелдерү максатыннан, бу театр Минзәләгә күчерелә. Җитәкчесе итеп Сабир Өметбаев билгеләнә.

Минзәләгә моңа кадәр Чистайда эшләгән Юныс Фарсин, Гыйләҗ Казанский, Гөлсем Йосыпова, Исмәгыйль Максудов, Татар дәүләт академия театрыннан Хәдичә Сәлимова, Чаллы труппасыннан Мөхәррәм Зәйнуллин, Камәрбану Шәмсетдинова, Рокыя Ибраһимова, Илеш театрыннан Газиз Мөхәммәтшин килә. Артистлар составы Казан татар эшче театрыннан килгән Рабига Шакирова, Гомәр Калинин, Мәрьям Калинина, яңа гына Татар театр техникумын тәмамлаган Гөлҗиһан Сәетова (соңрак Кичубаева), Мидхәт Рафиков, Нур Яһудин, Мөхит Кичубаев кебек сәләтле яшьләр хисабына тулыландырыла.

Театр биш-алты ел эчендә 40тан артык әсәрне сәхнәләштерә. 1939 елда театр Мәскәүдә уздырылган Бөтенсоюз колхоз-совхоз театрлары фестивалендә Т. Гыйззәтнең



**Чистай шәһәренең татар һәвәскәр коллективы (түгәрәге). 1930-1931 еллар**

«Чаткылар», Г. Камалның «Беренче театр»ы белән катнашып Диплом һәм йөк машинасы белән бүләкләнә.

1941 ел. Сугыш башлана. Театрның ирләр составы тулысынча фронтка китсә дә, эш тукталмый. Бөтен авырлык хатын-кызлар җилкәсенә төшә. Алар үзләре сәхнә коралар, кирәк чакта ирләр булып спектакльдә уйныйлар. Репертуар нигездә патриотик темага багышланган бер пәрдәлек әсәрләрдән, скетч, интермедияләр, концерт номерларыннан төзелә.

1957 елда театр Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында Юныс Әминовның «Язылмаган законнар» (режиссеры Сабир Өметбаев) һәм Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» (режиссеры Мулланур Мостафин) спектакльләре белән катнаша. Декададан соң театрга Минзәлә татар дәүләт драма театры дигән статус бирелә.

1996 елдан Минзәлә театры үзенең оештыручысы Сабир Өметбаев исемен йөртә.

1999 елда Минзәлә театрының реконструкцияләнгән бинасы ачыла. Бина ачылу тантанасында катнашу өчен Татарстан Республикасының ул еллардагы Президенты Минтимер Шәймиев килә.

Яңа бина ачылганнан соң 20 елдан артык вакыт узган. Заман белән бергә театрның таләпләре дә үсә. Театр бинасын кабат яңарту сорала. Хәзер театрда яңа яшь директор – Илнур Гайниев һәм җир җимертеп эшләр яшьтәге ике режиссер бар – Булат Бәдриев һәм Дамир Самерханов.

## ЛЕГЕНДАР САБИР ӨМЕТБАЕВ ҺӘМ АНЫҢ ДӘВАМЧЫЛАРЫ

Минзәлә театрының бүгенге баш режиссеры Булат Бәдриев фикеренчә, театр коллективы Сабир абый Өметбаев һәм Мулланур абый Мостафин биргән инерция буенча бара алган. Театрның легендар артистлары Илүсә һәм Фәез Бәдриевларның улы Булат үзе дә бу театрга яшьли кайткан. Дөрес, соңрак «дөнья күрергә» чыгып киткән.
Ә 2009 елда театрга 25 яшьлек яшь режиссер Дамир Сәмерханов килә.



**Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры директоры Илнур Зөфәр улы Гайниев**

Дамир Сәмерханов: «Татарстанда беренче булып «Мулла» спектаклен мин куйдым. 2009 ел иде ул. Без биш кеше Фәрит Бикчәнтәев курсын тәмамладык. Мине театр директоры Роберт Шәймарданов диплом эшен куярга дип Минзәлә театрына чакырды. Әсәрне дә директор үзе тәкъдим итте. Ул «Яңа татар пьесасы»на килгән өч уңышлы әсәрнең берсе иңде. Минем бәхетемә шушы «Мулла»ны кую насыйп булды. Аннары шушы театрга эшкә килдем».

Булат Бәдриев: «...Туфан Миңнуллинның иң беренче әсәре Минзәләдә куелган. Сабир абый куйган. Безнең максат – үз драматургларыбызны үстерү. Төрле чәчәкләр үссен дип, Конфуций әйткәнчә, репертуар клумбабызда төрле спектакльләр булсын – татар классикасы да, русныкы да, чит илнеке дә… Ләкин 70-80 проценты үзебезнеке булсын».

Илнур Гайниев: «Театрның үсеш концепциясе бик гади. Безгә форум-фестивальләр кирәк. Һәр театрның үз «изюминкасы» була. Ул бит театрны гына түгел, җирлекне дә таныта. Миңа калса, бу безгә җитеп бетми. Шуны булдыра алсак… Минзәлә театрына 85 яшь тулды. Без бит Камал театрыннан



И. Зәйниев.
«Ситса туй»



И. Зәйниев.
«Ситса туй»



У.Шекспир.
«Макбет»



И. Зәйниев.
«Ситса туй»



Аманулла.
«Ташлап китмә...»



Аманулла.
«Ташлап китмә...»




85 нче театраль сезон нәтиҗәләре буенча «Ел актеры» номинациясендә бүләкләнгән артист Илназ Хисмәтуллин

кала иң өлкән татар театрларының берсе. Әлегә мин үзебезне информацион киңлектә азрак дип саныйм. Шул нияттән реклама бүлеге дә булдырдык. Тырышабыз. Балачактан беләм – Минзәлә театры бит ул бөтен Россиядә гөрләп «на слуху» торган театр. Хәзер безгә бу җитми. Әлбәттә, мәгълүмати кырга шәп, көчле әсәрләр, фестивальләр белән керергә кирәк. Татарстанда ел саен театраль Сабантуй уза... Минзәләдә театр була торып, Сабантуй бер дә үткәрелмәгән. Менә шуны уздырасы килә».

* * *

Минзәлә театры үзенең гаиләләр театры булуы белән горурлана. «Безнең театрны «Гаиләләр театры» дип йөртәләр иде. Сабир абый яшьләрне берсен берсенә кушарга тырышкан. Әллә шуңамы – контроль көчле булды», – ди Татарстанның халык артисты Рәзилә Муллина.

«Балаларны өйдә калдырып ишекне ябып чыгып китәбез дә, елый-елый барам. Бәләкәй Булатны өлкәнрәкләр үзләре үстерделәр инде. Без бит гастрольләрдә иң киме 24әр көн йөрдек. Миннән хәзер дә көләләр, суыткычны тутырып полуфабрикат эшләп куя иде дип. 500ләп котлет ясап, морозильникка күбрәк сыйсын өчен котлетларны яны белән бастырып тутыра торган идем. Үзләре пешерәләр. Алар бик мөстәкыйль булып үстеләр. Кер дә юдылар, өйне дә җыештырып куялар иде», – дип дәвам итә ул.

Рәзилә һәм Рөстәм Муллиннар театрның «йолдызлы парлары» иде.

Театрда быел гына яңа пар кавышты: Рөстәм Зиннуров һәм Диләрә Кәримуллинаның никах туйлары булып узды.

Рөстәм Зиннуров: «Театр белән кызыксынган яшьләр күбәя бара. Безнең театрда да хәзер яшьләр күп. Әле быел гына дүрт яшь актер килде. Спектакль картлардан гына торса, яшьләр шундук: «Юк, нәрсәгә барыйм мин аларны карарга?» – диячәк. Сәхнәдә үз яшендәге артистларны күргәч, аларның да кызыксынуы арта».



**Театрның бүгенге труппасы**

Рәзилә Муллина: «Без кысылыбрак, рамкаларда яшәдек. Кисәтү ясасалар да, кабул итәргә өйрәнеп үстек, тиеш кебек кабул иттек. Хәзер яшьләр иркен. Аларның фикер йөртүе дә иркенрәк. Уйнау сәләте дә… карап торам да, «Ох!» диеп куям. Шулкадәр әйбәт уйнаган вакытлары бар! Яшьләр сәләтле. Кайчакта башка театрлардагы коллегалар белән очрашканда: «Яшьләр шулай инде хәзер», – дип зарланучылар да бар. Мин алар белән килешмим.

Минем чорым булды. Гел героиня иттеләр. Өлкәннәрнең кайсыдыр чәй китереп бирер иде, кайсыдыр чәчемне үрешер, кайсы күлмәгемне кигезешер иде. Бу бит аларның дәрәҗәсен төшермәде, күтәрде генә. Хәзер инде безнең яшьләргә юл бирер вакытыбыз җитте».

* * *

Минзәлә театрының халыкчан булуын да ассызыклыйсым килә. Соңгы елларда ул экспериментал спектакльләр дә куеп карады, «Кече шәһәр театрлары» кебек эре фестивальләрдә дә катнашты, катнашып кына калмады – «Өмет» номинациясендә Рөстәм Зиннуров лауреат булып та кайтты. Рус егете Влад Поджидаевны татарча спектакльдә уйнатып, контент булган очракта телгә кызыксындырып булуын раслады. Нинди генә проектларга алынмасын – театрның нигезендә халыкчанлык, миллилек ята. Ягъни, өсте суперзаманча проектның да эчендә милли хис ята. Бу фикерне Рәзилә Муллинаның сүзләре дә ачып бирә ала: «Мин ул чакларда калфаклар, алъяпкычлар чиктем. «Өч аршын җир» спектакленә дә сөлгене үзем чиктем. Калфакларны да күп кидем. Иван Грозныйның әнисе Глинскаяны уйнаганда урыс шапкасына татар милли бизәге чигеп куйдым. Бу бертөрле кирелек димме соң? Островскийның «Гроза»сында Кабаниханы уйнаганда да башта башыма чиккән калфакны «Бисмилла» әйтеп киям, аннары өстенә яулык бәйләп куям. Үземә шулай рәхәт».

Фоторәсемнәр Минзәлә татар дәүләт драма театры архивыннан

*Әңгәмәдәш –*
*Фәния ЛОТФУЛЛИНА*

# Сәйдә Мөхәммәтҗанова: «Мөнәҗәтләр тыңлап үстем»

БАЛАЧАКТАН ҮЗӘК КАНАЛ АША БӨТЕН ДӨНЬЯГА ТАТАР ҖЫРЫН ЯҢГЫРАТКАН «ГОЛОС. ДЕТИ» ПРОЕКТЫ ҖИҢҮЧЕСЕ СӘЙДӘ МӨХӘММӘТҖАНОВАНЫ БҮГЕН ОЛЫСЫ ДА, КЕЧЕСЕ ДӘ ЯРАТЫП ТЫҢЛЫЙ. МОҢЛЫ ТАВЫШЛЫ МИЛЛИ ҖЫРЧЫБЫЗ ТАТАР КЫЗЛАРЫНА ХАС БУЛГАН ГАДИЛЕГЕ, САДӘЛЕГЕ ҺӘМ ИХЛАСЛЫГЫ БЕЛӘН ТАМАШАЧЫ КҮҢЕЛЕН ЯУЛАП АЛДЫ. «КУНАКХАНӘ» РУБРИКАСЫНЫҢ КУНАГЫ – СӘЙДӘ МӨХӘММӘТҖАНОВА. ТОРМЫШЫНДА НИНДИ ЯҢАЛЫКЛАР БАР, КИЛӘЧӘККӘ НИНДИ ПЛАННАР БЕЛӘН ЯШИ – ШУЛАР ҺӘМ БАШКАЛАР ТУРЫНДА ӘҢГӘМӘ КОРДЫК.

**– Сәйдә, бу көннәрдә нинди эшләр белән янып йөрисең?**

– Бүгенге көндә ике уку йортында белем алам: Казан федераль университетының Көнчыгыш телләр бүлегендә һәм параллель рәвештә И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятендә укыйм. Университетта мин төрек теле өйрәнәм, II курстан гарәп һәм инглиз телләре керә башлады.

**– Син хәзер Казан филармониясендә эшлисең икән. Филармониягә эшкә килүең, киләчәгеңне иҗат белән бәйләвеңне аңлатадыр инде, әйеме?**

– Әйе, Аллаһ ярдәме белән, язмышым мине Казан филармониясенә китерде – 2020 елның ноябреннән Казан филармониясендә эшли башладым. Ике җирдә укысам да, иҗатымны дәвам итәм. Безнең коллективта бик көчле, затлы җырчылар һәм музыкантлар эшли. Алар белән бер мәйданда булу минем өчен горурлык. Алардан тәҗрибә тупларга, алар белән ешрак аралашырга тырышам.

**– Гаиләң турында да сөйлә әле. Синең иманлы, инсафлы, тәрбияле булып үсүеңдә, талантыңны кечкенәдән күреп, үстерә алуында әти-әниеңнең өлеше зурдыр.**

– Әлбәттә, әтием-әниемнең өлеше зур: 5 яшемдә җырга сәләтемне күреп, Абдулла Алиш исемендәге балалар иҗат үзәгенә җыр дәресләренә бирделәр. Анда мине Алсу Еникиева җитәкчелегендә эшләп килә торган «Ак калфак» фольклор ансамбленә солистка итеп куйдылар. Иҗатым нәкъ менә мөнәҗәтләрдән һәм бәетләрдән башланып китте. 6 яшемдә «Кунаклык» исемле мөнәҗәт башкарып, «Созвездие-Йолдызлык» бәйгесендә беренче урынны алдым.

Ходай биргән сәләтемне күреп, вакытында дөрес юлга кертеп җибәргән, шул юнәлешне үстерергә ярдәм иткән әти-әниемә бик рәхмәтлемен.





Мөнәҗәтләрне кечкенәдән тыңлап үстем. Дәү әнием Чистай районы Каргалы авылында яши. Аңа хәзер 87 яшь. Аның мөнәҗәтләр көйләгәнен бик яратып тыңлый идем. Татар халык җырларын да миңа ул өйрәтте. Кич утырганда дәү әнием белән җырлашып утыра идек. Аның үзенчәлекле көй бормалары икенче бер дөнья кебек. Ул миңа мөнәҗәтләр язылган китабын да бүләк итте. Әле дә хәтерлим, «Кешенең дүрт асылы» дигән мөнәҗәтен язып биргән иде. Соңрак, мин аны Зөһрә Сәхәбиева башкаруында ишеттем. Инстаграм битемдә дәү әнием белән бергә җырлап утырган видеоязмалар бар.

**– Сәйдә, соңгы вакытта иҗат иткән матур, сыйфатлы клипларыңны гел карап барырга тырышам. Аларга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та игътибар итә. «Кайтуыңны сагынырмын» исемле җырга клибыңны Youtube каналында 300 меңнән артык кеше караган. Бу җырның популяр булуының сере нидә?**

– Бу җырны миңа Искәндәр абый Мостафин тәкъдим итте. Үзе рояльдә уйнап, җырлап күрсәтүгә, күңелемә май булып ятты. Әлеге җырны яздырып кына калмыйча, аңа сыйфатлы һәм мәгънәле клип та төшерергә уйладык. Моның өчен «Туган тел» каналының Татарстан бүлеге җитәкчесе Миләүшә Сибгатуллинага мөрәҗәгать иттек. Ул клипның сценариесен язды. Клипта Фатих Кәрим әсәре буенча морза кызы Фатыймадан алынган сюжет линиясе ята. Анда – Исмәгыйль Гаспринскийның әти-әнисенең мәхәббәте. Аның әтисе ярлы бакчачы егет һәм әнисе морза кызы Фатыйма була. Алар әсәрдә кавышып бәхетле була. Ләкин безнең клипта җырның мәгънәсе дә, сюжеты да башка юнәлеш алды. Хәзер инде бу җырга трилогия ясавымны сорыйлар. Клип аша без мәдәниятебезнең бай тарихын күрсәтергә тырыштык. Минемчә, уңышлы килеп чыкты. Җырны Луиза Батыр-Болгари 1980 елларда ук иҗат иткән булган, ә Искәндәр Мостафин бу җырга яңа сулыш өрде.

**– Клипларыңны чыгарганда финанс ягыннан кем ярдәм итә?**

– Әйе, сыйфатлы әйбер эшләү зур чыгымнар таләп итә. Бу ике клипны («Кайтуыңны сагынырмын» һәм «Җырларым» ) без гаилә акчасына, ә соңгы проект – «Сөембикә моңы» җырын Татарстанның Мәдәният министрлыгы ярдәме белән эшләдек.

Пандемия вакытында әтием белән Луиза Батыр-Болгари янына Мари-Эльга барып кайттык. Ул безгә үзенең җырларын тәкъдим итте. «Сөембикә моңы» – кантата, ике өлештән тора. Беренче өлеше Сөембикә тарафыннан сөйләнә торган сүзләр. Икенче өлешен Илнар Шәрәфетдинов башкарды. Ул Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар егете. Минеке елау рәвешендә барса, аның өлеше дәртлерәк. Бүгенге көндә ике өлешнең дә клибы әзер.

**– Күптән түгел герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган җырың чыкты...**

– Башкортстанда туып үскән, бүгенге көндә Мәскәүдә яшәүче милләттәшебез Радмир абый Шәйхетдинов «Кайтуыңны сагынырмын» клибын күреп, миңа социаль челтәрләр аша элемтәгә чыгып, берничә җырын тәкъдим итте. Шулар арасында Муса Җәлил сүзләренә «Җырларым» җыры да бар иде. Шулай итеп аңа да клип яздырырга булдык, чөнки быел Муса Җәлилнең юбилее да.

Радмир абый белән иҗат иткән икенче җырыбыз – Мәҗит Гафури шигыренә «Бер гашыйкның сүзләре». Ул заманча һәм кызыклы килеп чыкты – босса-нова стилендә эшләнгән. Ә бу стиль бразиль музыкасы һәм джаз музыка белән берләштерелгән. Бигрәк тә яшьләргә туры килә. Әлегә татар дөньясында мондый төрдәге җырлар юк иде.

**– Сәйдә, иҗатыңны яратучылар белән беррәттән тискәре фикер җиткерүчеләр дә очрыйдыр. Тәнкыйтьне ничек кабул итәсең?**

– Тыныч карыйм. Кеше никадәр күп эшли, иҗат итә, шулкадәр көнләшүчеләр дә күп. Әмма тыңлаучыларымның 90-95% җырларымны хуплыйлар, яраталар һәм мин аларга бик рәхмәтле.

**– Бүгенге яшьләрне халык җырлары, классик җырлар белән җәлеп итеп буламы? Телебезне, милли мирасыбызны яшь буынга тапшырып калдыру өчен нишләргә кирәк?**

– Минемчә, бу эш гаиләдән килергә тиеш. Аннары инде дәүләт тарафыннан да. Хәзер радиолардан күп очракта эстрада ритмындагы җиңелрәк җырлар тыңлыйбыз. Бу тыңлаучының күңеленә сеңә. Миңа калса, татар җырында юнәлешләр күбрәк булырга тиеш.

**– Татар җырчысы татарча гына җырларга тиешме?**

– Җырчы иң беренче чиратта үз телендә аралаша һәм үз телендә җырлый белергә тиеш. Ә инде башка телләрдә дә җырлавы аны бөтен яктан да булган җырчы итеп кенә күрсәтә. Әгәр дә ул башка телләрдә оста, матур җырлый икән, нишләп әле андый мөмкинлектән файдаланмаска. Мәсәлән, безнең Әлфия Афзалова татар телендә генә җырламаган, башка телләрдә дә җырлаган.

**– «Голос» проектында син халкыбызның «Су буйлап» җырын башкарып, татар җырын бөтен дөньяга таныттың. Ул чакта сиңа татарча җырламаска да тәкъдим иткән булганнар икән.**

– Беренче сезонда мин халкыбызның «Сахралар» җырын тәкъдим иттем. Ләкин алар татар телендә җырламыйсың, чөнки наставниклар аңламый дип, кырт кистеләр, «Горница» дигән җырны башкарырга куштылар. Ләкин, Аллага шөкер, беренче сезонда миңа чират җитмәде. Беренче сезон узгач, репертуар сайлар өчен безне мөхәррирләр янына керттеләр. Шунда мин «Горница»ны җырламаячагымны әйттем. Аларга «Созвездие-Йолдызлык» фестивалендә җиңү яулаган «Су буйлап» җырын җырлап күрсәттем. Бер куплетын җырлагач, алар туктамавымны үтенделәр. Шулай итеп, өч куплетын да җырлап бетердем һәм җырны кабул иттеләр.

**– Әлеге проектта җиңеп кайткач, син популярлашып, танылып киттең. Мондый бәйгеләр баланың психикасына тәэсир итәме?**

– Әгәр син берәр бәйгедә катнашасың икән, үзеңне алдан әзерләргә кирәк.



Укытучы белән генә түгел, әти-әнием белән дә. Психологик яктан эчке дөньяң да әзер булырга тиеш. Конкурслар иҗатны да, психологияне дә ныгытырга булыша.

**– Сәйдә, синең сәхнә костюмнарыңда һәм, гомумән, бөтен образыңнан миллилек чагыла. Син гадәти тормышта да шулай киенәсең, үзеңне чын татар кызлары кебек тотасың. Синең шушы образыңны тудыру өстендә кем дә булса эшлиме, сәхнә киемнәреңне кем сайлаша?**

– Әти-әнием белән бергәләшеп сайлыйбыз. Монда инде минем өч таләбем бар. Иң мөһиме – гаурәт капланырга, озын итәкле, озын җиңле булырга тиеш. Миллилекне күрсәтер өчен без татар бизәкләре кертәбез. Соңгы елларда дизайнер Луиза Скипина белән актив эшлибез.

**– Гадәттә без кешенең гел уңай яклары турында гына сөйләшәбез. Синең тискәре сыйфатың бармы?**

– Мин ялкау. Бу гадәтемне яратмыйм. Һәм мин пунктуаль түгел. Дәресләргә дә соңга калып килергә мөмкинмен. Мине укыткан укытучыларым, бер үк гафу итә күрсеннәр.

**– Уйланганың бармы, хәзерге заманда батырлык нәрсә ул?**

– Яхшы сорау бу, уйландыра. Миңа калса, бүгенге көнгә кадәр үз милләтен саклап калган кеше иң батырыдыр.

**– Киләчәк тормышыңны ничек күз алдына китерәсең?**

– Хатын-кыз буларак иң беренче хыялым, әлбәттә, матур гаилә кору, балалар үстерү һәм иҗатымны дәвам итү. Икенчедән, татар җырын күбрәк кеше белсен өчен, аны тагын да популярлаштыру, бөтен дөньяга таныту. Милләттәшләремне туган телебездә сөйләшергә өндим. Гореф-гадәтләребезне, мирасыбызны саклап калып, киләчәк буыннарга да җиткерергә язсын иде.

Фоторәсемнәр Сәйдә Мөхәммәтҗанованың шәхси архивыннан




*Татарстан китап нәшриятында татар һәм рус телләрендә «Идел буе халыклары әкиятләре» дигән китап дөнья күрде. Анда башкорт, мари, мордва, рус, татар, удмурт, чуваш халык әкиятләре урын алган. Китапны төзүче һәм татар теленә тәрҗемә итүче – Фәнзилә Җәүһәрова. «Әлеге китапка тупланган әкиятләрнең уртаклыклары шактый. Ул уртаклыклар әкият геройларының зирәклегендә, ярдәмчел булуларында, каршылыкларны җиңеп, куйган максатларына ирешергә тырышуларында, яхшылыкның начарлыктан өстен булуында, алдакчы-хәйләкәрләрне урыннарына утыртып, тормышны алардан башка алып барырга өйрәтүләрендә.  Болар, әлбәттә, Идел буе халыкларының борынгы заманнардан бирле үзара тыгыз аралашулары, бер үк рухи кыйммәтләргә өстенлек бирүләре турында сөйли.*

*Әлеге халык җәүһәрләре аркылы бер-беребезнең рухи халәтен, кыйммәтләрен тирәнрәк кабул итәргә, шуның бәрабәренә күршедә яшәүче халыкларыбыз мәдәниятенә хөрмәт белән карарга өйрәнерсез дип өметләнәбез», – дип яза ул сүз башында.*

# АК ЕЛАН

Бер хан бар иде. Ул беркөн төш күрде. Иртәгесен йортка яр салды:

– Кем дә кем, алдыма килеп, төшемдә ни күргәнемне әйтсә, аңа бер тылуб тыла[1] бирәм. Әгәр дә алдыма килеп, күргән төшемне әйтә алмаса, башын кисәм.

Янә ул заманда бер бик ярлы, фәкыйрь ир бар иде. Ул ирнең хатыны, иренә дошман булып, һәрдаим аны үтерү нияте белән йөри иде. Шушы хатын, әлеге сүзне ишетеп, хан каршына килде һәм әйтте:

– Патшакаем, төшеңнең тәгърифен[2] минем ирем белә, белсә дә әйтми, – диде.

Хан, хатын сүзенә ышанып, шунда ук кеше җибәреп, ул байгышны чакыртты. Мескенчәк юлда бу хәлгә зар елап, Тәңрегә тилмереп вә аннан ярдәм сорап, җаныннан өмет өзеп килгәндә, аңа Ак елан очрады. Елан сәлам бирде. Бу фәкыйрь галәйкә[3] бирде.

Елан сорады:

– Әй адәм, кая барасың вә каян киләсең, вә ни өчен елыйсың? Бу фәкыйрь хәл-әхвәлен сөйләп бирде:

– Ханыбыз бер төш күргән. Кем дә кем төшемне юрый, шуңа бер тылуб тыла бирәм, юрый алмаса, башын кисәм, дип әйткән.

Елан әйтте:

– Хәваһласаң[4] барырсың, хәваһламасаң бармассың.

Ир әйтте:

– Минем хатыным бар, ул – миңа дошман. Һәрвакыт мине үтерү нияте белән йөри. Бу хәбәрне ишеткәч, хан янына барып әйткән: «Синең күргән төшеңне минем ирем белә, белсә дә әйтми», – дип. Ханның кеше җибәреп мине алдыруының сәбәбе шул, – диде.

Бу сүзне ишетеп, Ак елан әйтте:

– Әгәр мин аның төшен сиңа әйтсәм, син үлемнән котыласың, ул бер тылуб тыланы миңа китереп бирерсеңме? – диде.

Фәкыйрь әйтте:

– Алтын белән көмештән җан яхшы. Әгәр үлемнән котылсам, берсе дә кирәкмәс – һәммәсен китереп бирермен, – диде.

[1] Тылуб тыла – йөз алтын.
[2] Тәгъриф – юрау.
[3] Галәйкә – сәламгә җавап.
[4] Хәваһ – теләк.



Елан әйтте:

– Барып керүең белән, хан синнән сорар: «Әй гариб[5], мин төшемдә ни күрдем?» – дип. Син җавабыңда: «Төшеңдә кашкар[6] күрдең», – дип әйт. Аннан соң ул сиңа бер тылуб тыла бирер, син ул тыланы һич тә хыянәтсез миңа китереп бир, – диде.

Бу сүзне әйткәч, Ак елан белән ир хушлаштылар. Елан – үз юлына, фәкыйрь хан янына китте. Менә ул хан йортына килеп җитте. Өенә керде, сәлам бирде. Хан да галәйкә бирде. Аннан:

– Әй гариб, мин төшемдә ни күрдем, әйт?! – диде.

Гариб:

– Син кашкар күрдең, – дип әйтте.

Хан шунда ук бер тылуб тыла бирде. Гариб, патша сараеннан чыгып, Ак еланга бармыйча, туры өенә качып кайтты. Аннан соң ул тылага бик күп елкы, хайваннар һәм мал сатып алды. Бай булды. Көн күрүе яхшырды.

Бер вакыттан соң хан янә бер төш күрде. Тагын гарибне чакыртты. «Әгәр тапса, бер тылуб тыла бирәм, тапмаса, башын кисәм», – диде. Бу гариб электә бик ярлы иде, бай булды. Хәзер җаны элеккедән дә татлы иде. Бик каты елады. Ахырда чарасызлыктан: «Барам!» – диде. Торды да юлга чыкты. Юлда бик зар елап, җаныннан өмет өзеп килгәндә, баягы Ак еланга тап булды. Гариб сәлам бирде.

Елан галәйкә бирде дә:

– Әй гариб, кая барасың һәм ни өчен елыйсың? – диде. Гариб әйтте:

– Хан тагын төш күргән, «белсә, бер тылуб тыла бирермен, белмәсә, башын кисәрмен» дип, мине төшен юрамакка чакыртты. Инде башымның китүе шулдыр.

Елан әйтте:

– Мин беләм, ләкин сиңа әйтмим. Син теге вакытта миңа ялганладың, тыланы бирми алдап качып киттең.

Гариб:

– Бу төшнең тәгърифен әйтсәң, мине бу үлемнән коткарсаң, монысын гына түгел, алдагы тыланы да китереп бирермен, – дип ант эчте.

[5] Гариб – ярлы, фәкыйрь.
[6] Кашкар – бүре.



Елан әйтте:

– Бу юлы алдама. Башка бер вакытта да кирәк булырмын. Инде әйтим, ханга барып сәлам бир дә: «Син Төлке күрдең», – дип әйт. Аннан, бер тылуб тыланы алып, кире миңа кайт.

Гариб, бу сүзне ишетеп, шат булып, хан янына килде. Сәлам бирде. Хан сорады:

– Мин төшемдә ни күрдем, әйт?!

Гариб:

– Син Төлке күрдең, – диде. Хан бер тылуб тыла бирде.

Гариб, Ак еланга бармый, тагын өенә качып кайтты. Элеккедән дә бай булды, уйнады, көлде. Байлыгына горурланып, тәкәбберләнеп йөрде. Баягы хан янә бер төш күрде. Янә әлеге гарибне дәштерде. «Тапса, бер тылуб тыла бирәм, тапмаса, башын кисәм!» – диде. Ир, бу сүзне ишеткәч, тагын да катырак елый башлады: «Ак еланны алдадым, бу вафасыз дөньяда кала торган мал өчен бит», – диде. Авырлык белән юлга чыкты. Җаныннан өмет өзеп килгәндә, каршысында янә Ак елан пәйда булды. Моны күреп әйтте:

– Ялганчы гариб, ике үлемнән котылдың, өченчесендә тотылдың.

Гариб әйтте:

– Әй Ак елан, мине ике үлемнән азат кылдың, мин, синең кадереңне белми, ул яман эшләрне эшләдем, инде тәүбәгә килдем. Бу үлемнән азат итеп, аталык мәрхәмәтен, аналык шәфкатен кылсаңчы. Әүвәл – Алла каршында, икенче үзең каршыңда кыямәт көнне мәхшәрдә миңа ялганчылык атын кушма. Дөнья эшен дөньяда бетерим һәм сиңа бирәчәк тылаларның барчасын тапшырып китим.

Ак елан бу сүзне хуш күрде, әйтте:

– Бар, ханның өенә кер, сәлам бир. Ул синнән сораса: «Ни күрдем?» – дип, син әйт: «Төшеңдә куй күрдең», – диген. Ул сиңа бер тылуб тыла бирер. Син ул тыланы алып килеп миңа бир.

Аннан соң ир Ак елан белән саубуллашып китте. Патша сараена җитте. Әй эченә кереп исәнләште. Хан да галәйкә бирде:

– Әй гариб, мин төшемдә ни күрдем?! Гариб әйтте:

– Син куй күрдең, – диде.

Хан бер тылуб тыла бирде. Ир, тыланы алып, Ак еланга килде. Сәлам бирештеләр. Ир әйтте:

– Синең хәер-догаңда сау-сәламәт кайттым. Җаным михнәт чикмәде. Кабул ит, менә бездәге әманәт тылаң һәм өемдәге ике тылуб тыланы да сиңа китереп бирәм. Мин борынгы



ике тылуб тыланы да сиңа бирергә ихлас күңелем белән ният кылган идем, белмим, ничек бирә алмадым. Хәзер дә акылсызлыгыма хәйран каламын.

Моңа каршы Ак елан:

– Егет, мин сиңа моның ни өчен шулай килеп чыкканлыгын әйтим, син яхшы тыңла: әүвәл хан бүре күрде. Ул заманда һәм ханның, һәм ил-йортның бүре булган вакыты иде. Бүре яхшылык белми. Шуңа күрә син дә, вәгъдәңдә торып, тылубны миңа бирмәдең. Аннан соң хан төлке күрде. Ул вакытта ил-йорт төлкедәй алдакчы булды. Шуның өчен син дә миңа ялган сүзләр әйтеп алдадың. Соңгысында хан төшендә куй күрде һәм золымлыгын ташлады, гадел булды, ил-йорт та тугры булды. Хан залим булса, ил-йорт тәртипсез, угры, үтерүче булыр. Хан гадел булса, йорт тугры, инсафлы, суфи булыр. Синдә гаеп юк, гаеп ханда. Хан, төшендә бу өч хайванны күреп, тәүбәгә килде. Син дә миңа тыланы китердең. Ил-йорт яман булганда, син дә яман булдың; яхшы булганда, син дә яхшы булдың. Һәрвакыт ил-йорт белән бергә булдың. Тыла үзеңә хәләл булсын! – диде дә күз алдыннан югалды.

**Булат Гыйлванов рәсемнәре**

*Гөлшат ХӨСӘЕНОВА,*
*Арча, Мөндеш авылының «Кояшкай» балалар бакчасы*
*музыка җитәкчесе*

# АУЛАК ӨЙ

(МӘКТӘПКӘ ХӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН
ҖЫРЛЫ-БИЮЛЕ МУЗЫКАЛЬ КҮРЕНЕШ)



Зал халыкчан, ләкин заманча стильдә бизәлә: чиккән сөлгеләр эленә, өстәлдә – самовар һәм татар халык ашлары, татар орнаментлары белән көянтә-чиләкләр, каз канатлары...

*(Чишмә буенда ике кыз очраша. Кулларында көянтә-чиләк. «Чиләк-көянтә» җыры яңгырый. И. Хәснетдинов көе, А. Фәйзрахманов сүзләре.)*

**Беренче кыз (Динә):**
– Сәлам, Азалия! Хәлләрең ничек? Әниләр кунакка киттеләр, әйдә суыңны өегезгә илтеп куй да безгә кил! Дус кызларны да чакырдым.
**Икенче кыз (Азалия):**
– Рәхмәт, Динә. Хәзер килеп җитәм.
*(Икесе ике якка китә. Сәхнәнең икенче ягында берничә кыз чигү чигеп утыра. Фон итеп «Сөлге чигәм» җыры яңгырый. Кызлар чиккән арада Динә өенә суын илтеп килә һәм кызлар янына чыга.)*
**Беренче кыз (Динә):**
– Карале, кемдер ишек шакый. Әллә Азалия килеп тә җиткән инде? *(Тәрәзәдән карый.)*
**Азалия** *(керә):*
– Кызлар, сәлам!
**Кызлар** *(бергә):*
– Сәлам, Азалия. Кер әйдә!
**Динә:**
– Кызлар, ишеттегезме, түбән очка кунак егете Алмаз кайткан ди.
**Бер кыз:**
– Шулаймени? Ишетмәдек...
**Динә:**
– Әти белән әни бүген кунакка киткәндә әйттеләр.
**Икенче кыз:**
– Бәлки, егетләрне аулак өйгә чакырырбыз?
**Кызларның барысы бергә:**
– Әйдәгез!
*(Кызлар «Аулак өй» җырын башкара. З. Минһаҗева сүзләре, В. Әхмәтшин көе.)*
**Динә** *(тәрәзәдән карап ала):*
– Кызлар, кызлар, егетләр үзләре килә түгелме соң? Кертәбезме?
**Азалия:**
– Кертик, кызлар! Әзрәк утырырлар да кайтып китәрләр.
*(Егетләр сәхнә читеннән – «өйгә кермичә генә», ерактан дәшәләр.)*
– Исәнмесез, кызлар-йолдызлар!
**Кызлар** *(егетләргә):*
– Исәнмесез!
**Азалия:**
– Егетләр, сезгә кем кирәк?
**Төп герой, гармунчы егет (Алмаз):**
– Кара кашлы кыз кирәк! Кызлар, ачыгыз инде ишекне!
**Азалия:**
– Ишек бавы бер алтын – безнең кызлар мең алтын!
**Алмаз:**
– Кызлар, кертегез инде.
**Азалия:**
– Ярый инде, керсеннәр.
*(Алмаз гармунда уйный-уйный керә, артыннан егетләр тәркеме «өйгә» уза).*
**Егетләрнең икенчесе (Ислам):**
– Исәнмесез, ка-азл-а-а-ар!
**Азалия:**
– Кемнәр? *(Аптырап сорый.)*
**Ислам:**
– Әй, кызлар инде, кызлар! Хәлләрегез ничек, йолдызлар?
**Кызларның барысы бергә:**
– Бик әйбәт!
**Алмаз:**
– Уйныйбыз да, җырлыйбыз да,
Гармун кулларыбызда.
Алсу гөлләр чәчәк атсын,
Йөргән юлларыгызда.
**Кызларның берсе (Лиана):**
– Ал да итәрбез әле,
Гөл дә итәрбез әле.
Матур җырлар җырлый-җырлый,
Бәйрәм итәрбез әле.
**Егетләрнең берсе (Ислам):**
– Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлап ачыла күңел.
Җырлап ачылмаган күңел
Мәңге ачылачак түгел.
*(«Шома бас» татар халык җыры ярыш формасында башкарыла. Егетләр кызлар каршысына басып җырлый: бер куплет – кызлар, икенче куплет – егетләр, өченчесен – бергәләп.)*
**Азалия:**
– Кызлар-егетләр, әйдәгез борынгы уеннарның берсен – «Йөзек салыш» уенын уйнап алабыз.
*(«Йөзек салыш» уены. Барысы да бер рәткә тезелеп басып уйныйлар, фон булырак татар бию көе яңгырый.)*
*(1 нче җәза Алмазга бирелә.)*
**Лиана:**
– Алмазны нишләтәбез?



**Ислам:**
– Дуслары белән җырлап-биеп күрсәтсен.
*(Татар халык көйләренә тезмә-трио башкарыла.)*
*(2 нче җәза кызларның берсенә бирелә.)*
**Алмаз:**
– Я, Нурзиләгә нинди җәза бирәбез?
**Ислам:**
– Дус кызлары белән биеп күрсәтсен.
*(Кызлар татар халык биюе «Каз канаты»н башкаралар. Кызларның кулларында каз канатлары. Бу вакытта егетләр тиз генә йон оекбаш, галош киеп чыга.)*
**Динә:**
– Исламга нинди җәза бирәбез?
**Азалия:**
– Дуслары белән бер җырласын!
*(«Бәрәңге җыры»н башкаралар. И. Хисамов көе, М. Хөсәен сүзләре. Егетләрдә татар костюмы, аякта галош белән йон оекбаш, бераз декорацияне үзгәртергә мөмкин.)*
**Динә:**
– Безне матур бии диләр,
Биеп күрсәтик әле...

*(Кызлар белән егетләр «Көтүчеләр биюе»н башкара.)*

**Алмаз:**
– Әйдәгез бер уйнап та алабыз.
*(«Чума үрдәк, чума каз» уены. 3 пар уйный, бу вакытта калган кызлар чигү чигеп утыра.)*
**Азалия:**
– Милләтемнең гасырлардан килгән
Истәлекле гадәтләре бар.
Күркәм гадәтләрне яшәтүче
Олуг телем – татар теле бар!
**Динә:**
– Онытылган гореф-гадәтләрне,
Яңартабыз хәзер көннән-көн.
Уен-йолалары, җыр-биюе,
Һәр киләчәк көнне бизәсен.
**Алмаз:**
– Әйдәгез бер җырлыйк әле,
Уйнаган гармуннарга.
Ал чәчәк күк яшик әле,
Туган якларыбызда.
*(«Матур булсын» – татар халык җыры. Кызлар гына җырлый, җырның соңгы куплетында егетләр кызларның һәркайсына чәчәк бүләк итә.)*

**Автор фоторәсемнәре**

# Җәяүле
# буран

Резеда Вәлиева сүзләре,
Наилә Яхина көе




Юллар буйлап
Очып уйнап,
Җәяүле буран йөри.
Әле чәчә ул карларын,
Әле тау итеп көри.

***Кушымта:***

*Әйләнә дә килеп үтә,*
*Әйләнә дә килеп үтә,*
*Тау битенә сырпаланып,*
*Безгә кар сибеп китә.*

Без, тотмакчы булып аны,
Йөгереп чыксак юлга,
Ак койрыгын болгап-болгап,
Ялт күздән югала.

***Кушымта.***



# ҮРДӘК *итеннән бәлеш*

БҮГЕН БЕЗДӘ КУНАКТА – МЕНДЕЛЕЕВСК РАЙОНЫНЫҢ ТОЙГУҖА АВЫЛЫНЫҢ МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ ДИРЕКТОРЫ, «ДӨРЕШКӘЙ» ТЕАТРЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ГӨЛНАРА ГЫЙНИЯТ КЫЗЫ ГАЙФЕТДИНОВА.

– Мин Чаллы кызы булсам да, балачагым авылда – әбиләремдә үтте. Әтиемнең әнисе Мөхлисә әби Менделеевск районының Рус Сарсазы авылында яшәсә, әниемнекеләр – Хәмдия әби белән Нургали бабай Әтәс авылында тордылар. Авыл булгач, кош-корт асрап яшәделәр, казлары күп була иде. Нургали бабай каз итен банкаларга салып, тозлап куя да, әби шул иттән бәлеш пешерә. Бигрәк тәмле була иде ул тозлы иттән бәлеш. Авылда матур итеп каз канаты үрүче дә минем бабай иде. Канат үрдерергә бөтен авыл халкы килә иде аңа.

Ике әбиемдә дә мич бар иде. Без, бала-чага шул мич өстенә менеп йоклый да идек әле. Иртән арка җылынганга, тәмле искә уянып китәбез. Ә анда әби мичтә коймак пешерә...

Авылга күчеп кайткач, әнием дә мичне сүттермәде. Ул да мичтә пешеренергә ярата. Ел саен ул мичне карап, буяп торабыз.

Мин авыл үрдәгеннән пешерелгән бәлеш яратам. Журнал укучыларына да бүген шуны тәкъдим итәм. Бәлешне төрле итләрне катнаштырып та пешерергә була, мәсәлән, сыер ите янына үрдәкнекен, ат ите янына казныкын, сарык ите янына сыер итен, сыер ите янына тавыкныкын кушарга була, – ди Гөлнара ханым.

КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**Камыр өчен:**

**150 грамм көнбагыш мае,**
**150 грамм кайнаган су,**
**0,5 чәй кашыгы шикәр комы,**
**1 чәй кашыгы тоз,**
**0,5 чәй кашыгы сода,**
**йомшак камыр килеп чыгарлык он.**

**Эчлек өчен:**

**1,5-2 килограмм бәрәңге,**
**0,5 килограмм үрдәк ите,**
**2-3 баш суган,**
**1 данә лавр яфрагы,**
**1 стакан шулпа,**
**түменчә борыч, тоз, әнис орлыгы.**

## Җиде сорау

**1 – Татар хатыны пешерә белергә тиешле өч ризык?**

– Минемчә, татар хатыны токмачлы аш, бәлеш, гөбәдия пешерә белергә тиеш.

**2 – Татар ир-аты яраткан өч ризык?**

– Ир-атларның яратмаган ризыгы юктыр ул. Итле бәлештән, гөбәдиядән, кыстыбыйдан кайсы ир-ат баш тартсын икән?! Белмим, мин нәрсә пешерсәм дә, «тәмле» дип ашыйлар. Бигрәк тә, гөбәдиямне яраталар. «Камыры авызда эреп тора», – дип мактыйлар.

**3 – Ир-ат йөрәгенә юл ашказаны аша, дигән сүз белән килешәсеңме?**

– Килешәм. Табының мул, телеңдә тәмле сүз булса, әлбәттә, ир-атка ошый. Гомумән, безнең татар хатыннарының өстәле ризыклардан сыгылып тора. Һәм аның шулай икәненә башка милләт кешеләре дә игътибар итә.

**4 – Балачак нинди ризыклар белән хәтереңә уелып калды?**

– Балачагымны искә төшергәндә, күз алдыма әбиемнәр килеп баса. Мөхлисә әбиемнең мичтә пешергән коймагын, Хәмдия әбиемнең ипиен, кабак боткаларын сагынам. Күп итеп пешкән коймак икенче көнгә дә кала иде. Икенче көнне инде әби аны табада кыздырып бирә, ул кетер-кетер килеп тора...

**5 – Гастрольләрдә йөргәндә кайсы якта нинди милли ризыклар белән сыйлыйлар? Моңарчы күз күрмәгән, ят ризык ашаганың булдымы?**

– Шулай бервакыт Әгерҗе районының Тәбәрле авылына бардык.Тәмле ризыклар тулы өстәл белән каршы алдылар. Бераздан әле яңа гына пешеп чыккан өчпочмак чыгардылар. Аның тәмлелеген әле дә онытмыйм. Югыйсә, өчпочмак пешергән дә, ашаган да бар. Ә боларның бөтенләй башкача тәмле, үзенчәлекле. «Һәр кешенең үз кул тәме бар шул», – дип уйлап куйган идем шул чагында.

**6 – Көннәрдән бер көнне Гөлнара Гайфетдинова ресторан яисә кафе ачса, фирменный ризыгың нәрсә булыр иде икән?**



– Сез минем хыялымны белеп сорыйсыз бугай. Чыннан да, күптәнге хыялым бит бу минем. Ресторан ук булмаса да, кереп ашап чыга торган берәр татар йорты ачар идем. Кунакларны каршы алырга, спектакльдән соң «Дәрешкәй» артистлары белән чәй эчәргә, авылда яшәүче ялгыз кешеләрне сыйларга менә дигән йорт булыр иде ул. Анда мич, мичтә пешкән коймак, чуенда пешкән аш, мичтә пешкән кабак боткасы, бәлеш булыр иде. Исемен аның да театрыбыз кебек, «Дәрешкәй» дип атар идем.

**7 – Француз мәкале: хатын-кыз юктан да скандал, салат һәм эшләпә ясый белә, ди. Эшләпә ясый аласыңа ышанам, ә скандал белән салат ясый алыр идеңме? Ул юктан гына ясалган салатның рецепты ничек?**

– Скандал ясарга бөтенләй яратмыйм – кәефне төшерә. Ә менә бик яратып ясый һәм ашый торган салатым бар. Аның өчен ысланган тавык ите, ананас, йомырка һәм сыр кирәк. Барысын да турап, сырны угычта уып саласың да майонез белән болгатасың, бик тәмле салат килеп чыга.



1. Алда әйтелгән барлык ингредиентларны кушып, йомшак кына камыр басабыз. Ясагач, целлофан пакетка салып, камырны 20 минут ял иттерәбез. Эчлекне ясаган арада, җылынсын өчен мичне 200 градуска кабызып куябыз.



2. Эчлек ясыйбыз: вак итеп суган, ит, бәрәңге турыйбыз. Тәменчә тоз, борыч, әнис орлыгы, лавр яфрагы салып болгатабыз.



3. Камырны төрле зурлыктагы 3 кисәккә бүләбез. Иң зур кисәкне җәеп, уртасына эчлек салабыз.



4. Икенче кисәкне җәеп, бәлеш өстенә каплап бөреп чыгабыз. Кечкенә өченче кисәктән капкачка тоткыч ясап куябыз.



5. Әзер бәлешне 180 градуслы кайнар мичкә куеп, 1 сәгать пешерәбез. Аннары мичтән алып, бәлешнең уртадагы тоткычын ачып эченә алдан әзерләп куйган 1 стакан шулпаны салабыз да, тагын 1 сәгатькә кайнар мичкә тыгабыз.



6. Пешеп чыккач, табынга чыгарыр алдыннан парлансын, тагын да йомшарсын өчен бәлешне бераз тастымал белән каплап тотабыз.

***Ашларыгыз тәмле булсын!***

Гөлсара Закирова фоторәсемнәре

# Шахворд

Хөрмәтле укучылар! Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән шахмат фигураларының (ферзь, ладья, ат) дөрес йөреш тәртибен кулланып, язучы, шагыйрь Галимҗан Гыйльмановның «Иртә белән» шигырен укыгыз.

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
|  | Ж | җ | ы | ы | к | н, | Б | ы | н | Г | а | ә | м- | и | ә | д |
| ы | – | л | л | ө | е | е | ю | а | а. | җ | н | ү | н | ү | н | и |
| п | ы, | р | н | г | р | ш | т | т | ә | ә | з | ә | з | и | ч | т |
| н | у | б | у | к | о | ы | ш | п | л | е | н | е | н | и | с | а! |
|  | р | ә | ә | г | ы | к | ы | н | К | о | а | д | о | е | А | н |
| ч | и | м | д | е | ч | с | у | д | а | е | н | а | к | н | а. | ы |
| н | л | ы | с | ы | м | а | н | т | о | е | л | а. | | | | ң |
| а | Ж | ы | р | а | л | ы | ч | м | а | т | н | ә | к | ч | ә | ч |
|  | К | т | ы | п | а | г | е | ы | г | л | ы, | л | ы | л | а | а |
| а | а | н | ы | л | и | н | ш | ы | а | т | м | д | Я | н | т | ң |
| н | а | к | а | н | ә | м | н. | ф | ы | ы | и | р | д | ы | ч | ы |
| ы | ш | Н | ә | т | о | Ш | и | л | с | л | ә | а | г | ы | г | н... |
|  | к | з | о | ы | е | и | л | ы | и | т | р | г | ә | й | е | о |
| р | к | ю | к | ч | ш | н | р | с | а | р | м | а | к | а | л | ө |
| | и | ә | | | | | | | | | | | | | н | б |
| ы | | н, | | а | – | м | л | м | и | а | м | р | к, | т | р | е. |
| Т | | г | | ы | е! | д | п | н | ә | а | Ч | к | и | у | е | ы |



Ферзьнең йөреш тәртибе



Ладьяның йөреш тәртибе



Ат «Г» хәрефе буенча йөри

Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем фәннәре академиясе академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде

**Шахвордның җавабы:**

**Иртә белән**

Җып-җылы, нурлы көн бүген,
Бер кош юына тышта.
Гаҗәпләнәм – үзе нәни,
Ә үзе нинди чиста!

Чирәмдәге чык суында
Коена да коена.
Аның чәчкән тамчылары
Җанлы сыман тоела.

Канатына ышкып ала
Нәни генә томшыгын.
Шифалы, тылсымлы диләр
Яландагы таң чыгын...

Юынырга оныткнамын,
Тизрәк керим әле.
Урамдагы кошлар кебек,
Чип-чиста йөрим әле!

# Истәлекле даталар
# 2022

## ГЫЙНВАР

**1 гыйнвар**

Язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге премиясе лауреаты Айдар (Борис) Нәҗметдин улы Хәлимгә (Хәлимов) 80 яшь (1942)

**1 гыйнвар**

Актёр, Татарстанның халык артисты Әсхәт Әсәдулла улы Хисмәтовка 70 яшь (1952)

**2 гыйнвар**

Сәнгать белгече, сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Фуад кызы Вәлиева-Сөләймановага 70 яшь (1952)

**2 гыйнвар**

Журналист һәм язучы, рәссам Дания Заһретдин кызы Гайнетдиновага 70 яшь (1952)

**2 гыйнвар**

Язучы-прозаик Фирдәвес Зәбихулла улы Зарифка (Зарифуллинга) 60 яшь (1962)

**3 гыйнвар**

Күренекле шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Зөлфәтнең (Дөлфәт Госман улы Маликов) тууына 75 ел (1947-2007)

**4 гыйнвар**

Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, дәүләт эшлеклесе, ТАССРның һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Разил Исмәгыйль улы Вәлиевкә 75 яшь (1947)

**5 гыйнвар**

Композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Виталий Вакыйф улы Харисовка 60 яшь (1962)

**6 гыйнвар**

Актёр, ТАССРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ирек Вәли улы Баһмановның тууына 90 ел (1932-2015)

**6 гыйнвар**

Рәссам, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б. Урманче исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Булат Әлфир улы Гыйлвановка 50 яшь (1972)

**20 гыйнвар**

Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе, «Яңарыш» республика фонды Химаячеләр советы рәисе, Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә 85 яшь (1937)

**23 гыйнвар**

Шагыйрь, прозаик, драматург, публицист, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе Ркаил Рафаил улы Зәйдуллага (Зәйдуллин) 60 яшь (1962)

## ФЕВРАЛЬ

**3 февраль**

Хор дирижёры, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Ирнис Әхмәдулла улы Рәхимуллинга 80 яшь (1942)

**8 февраль**

Театр белгече, ТАССРның һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе Ильтани Исхак кызы Иляловага 90 яшь (1932)

**17 февраль**

Баянчы, музыка белгече, педагог, ТАССРның һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе Рәгъде Фатыйх улы Халитовка 80 яшь (1942)

**23 февраль**

Рәссам, сынчы, график һәм педагог, ТАССРның, РСФСРның халык рәссамы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Бакый (Габделбакый) Идрис улы Урманченың тууына 125 ел (1897-1990)

## МАРТ

**1 март**

Балалар язучысы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Ләлә Нәгыйм кызы Сабировага (Гыймадиева) 75 яшь (1947)

**1 март**

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановка 65 яшь (1957)

**6 март**

Композитор, педагог, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мансур Әхмәт улы Мозаффаровның тууына 120 ел (1902-1966)

**9 март**

Композитор, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рим Мәхмүт улы Хәсәновка 75 яшь (1947)

**24 март**

Композитор, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Риф Вәҗетдин улы Ильясовның тууына 80 ел (1942-2017)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**









Кадерле укучыларыбыз!
2022 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

Индексыбыз – ПА 183
Өч айга язылу бәясе – 192 сум 67 тиен
Ярты елга язылу бәясе – 385 сум 34 тиен

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!